Тәрҗемә ысулына килгәндә, ул 1990-2000 нче елларда киң таралышка ия була. Уртаклык исеме белән мотивлашкан рус телендәге шәһәр атамаларының мәгънәләре татар теленә турыдан-туры тәрҗемә ителгән, мәсәлән: улица Дубравная – Имәнлек урамы, улица Родины – Ватан урамы. Бүгенге көндә әлеге ысул кулланылмый, чөнки урам исемнәре тәрҗемә итеп бирелми. Шул ук вакытта, реестрда кайбер атамаларның татар һәм рус формалары яшәве дәвам итә: улица *Победы – Җиңү* урамы; улица *Приволжская – Идел буе* урамы; площадь *Тысячелетия – Меңьеллык* мәйданы һ.б. Топонимнар нигезендә барлыкка килгән урбанонимнарның телдә кабул ителгән тәрҗемә варианты булса, шуның ярдәмендә бирелә: *Тюлячинская – Теләче* урамы; *Тюменская – Түмән* урамы; *Услонская – Ослан* урамы; *Челябинская – Чиләбе* урамы һ.б. [2: 294].

Казан шәһәрендә 2019 нчы ел ахырында барлыкка килгән яңа урам атамалары улица *Зеленая Роща – Зеленая Роща* урамы, *Алмазная* улица – *Алмазная* урамы; улица *Алтын – Алтын* урамы; улица *Айтуган – Айтуган* урамы; улица *Райхан – Рәйхан* урамы – бер телдә теркәлгән.

Атаманы катнаш ысул белән биргәндә, аның бер өлеше – оригинал телдә, икенчесе – кабул ителгән тәрҗемә формасында килә. Урам-юллар челтәренә караган объектлар тәрҗемә итеп бирелә: улица – урам, переулок – тыкрык, проезд – юл, площадь – мәйдан, слобода – бистә. Алынма булып торган сүзләр тәрҗемә ителми: проспект Ибрагимова – Ибраһимов проспекты; Оренбургский тракт – Оренбург тракты. Составында сан булган атамалар да өлешчә тәрҗемә ителә: 8-я Залесная – 8 нче Залесная урамы һ.б. Шулай ук урбанонимнар составында булган поперечно-, большая, малая,

старая, право-, лево- компонентлары кайбер очракларда тәрҗемә ителә: Большая Мухаметшина – Зур Мөхәммәтшин урамы (ләкин Большая Заречная – Большая Заречная урамы); Старо-Аметьевская – Иске Әмәт урамы (ләкин улица Старая – Старая урамы), һ.б. [2: 295].

Казан шәһәре урам атамаларын төзелеш-ясалыш ягыннан (тамыр, кушма, тезмә, ясалма) төрләргә бүләргә мөмкин:

I. Тамыр урбанонимнар: Дулкын, Лачын, Мирас, Намус, Сөенеч, Уңыш, Урман, Уртак, Хыял, Өмет, Энҗе, Юмарт һ.б.;

II. Ясалма урбанонимнар:

а) кушма урбанонимнар: Аккош, Алчәчәк, Балачак, Гөлбакча, Сабантуй һ.б.;

ә) тезмә урбанонимнар: Абдулла Алиш, Адмирал Ушаков, Ак каен, Ерак Кабан, Казан яшьләре Матур тыкрык, Су Анасы, Таллы яр һ.б.;

III. Ясагыч кушымчалар ярдәмендә ясалган урбанонимнар:

*-лык/-лек:* Агачлык, Батырлык, Дуслык, Туганлык, Яшьлек, Изгелек һ.б.;

*-чы/-че*: Елгачылар, Күперчеләр, Тамчы, Игенче һ.б.;

*-лы/-ле*: Наратлы, Затлы, Каенлы, Кояшлы, Назлы, Нурлы Серле һ.б.;

*-даш/-дәш*: Сердәш, Замандашлар, Юлдаш, Якташлар һ.б.;

*-гач/-гәч*: Алмагач һ.б.

Күп урбанонимнар реестрда бер телдә генә бирелә. Андыйларга түбәндәгеләрне кертергә мөмкин: Алтын Балык, Боевая, Главная, Дуслык, Игелекле, Игенче, Иман, Каенлы, Красивая, Лучистая, Матур, Назлы, Намус, Нурлы, Сабантуй, Татарстан, Ташаяк, Угловая, Центральная, Яз, Якташлар һ.б.

«Казан шәһәре атамалар реестры турында» карары нигезләмәсендә Казан шәһәрендә булган барлык урбанонимнар да урын алган. Урам атамалары язылышында төрле елларга хас: транслитерация, тәрҗемә, катнаш һ.б. ысулларның өстенлек итүе, урбанонимнар язылышында күп хаталарга китерә, бу бигрәк тә татар хәрефләре бирелешенә аеруча зур йогынты ясый. Мондый каршылыкларга очрамас өчен һәр атаманы рәсми документларга теркәгәнче, тел галимнәре белән берлектә аерым утырышлар булдыру һәм бердәм язылу ысулына таяну мөһим.

**Әдәбият**

1. Саттаров Г.Ф. Ни өчен шулай аталган? – Казан: Татар. кит. нәшр., 1971. – 127 б.
2. Татар лексикологиясе: өч томда / проект җит. М.З. Зәкиев; ред. Г.Р. Галиуллина. – Казан: ТӘһСИ, 2017. – Т. III. 1 кис. – 536 б.

## ЭМОЦИЯЛӘРНЕ БЕЛДЕРҮДӘ СИНОНИМЛЫК МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ

*Әминова Г., КФУ, III курс студенты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Э.Н. Денмөхәммәтова*

Эмоция – кешенең хисләре, кичерешләре, тойгылары, дип бирелә аңлатмалы сүзлектә [5: 574]. Нинди дә булса хис – кичерешне, эмоцияне белдерү өчен сөйләмдә катып калган гыйбарәләр, фразеологизмнар, терминнарны куллана ала. Алар, үз чиратында, язма сөйләмдә синонимик

рәтне хасил итәләр. Эмоцияләрне белдерүче чаралар тел белән генә түгел, ә психологик, тарихи, этнографик һәм культурологик факторларга да бәйле. Эмотив лингвистика нәкъ менә кеше эмоцияләренең телдә белдерелү чараларын өйрәнә. Хис – кичерешләрнең вербальләштерелүе телләрдә төрлечә чагыла ала. Матур әдәбият контекстында билгеле бер ситуацияләрдә теләсә нинди сүз эмотив коннотация алырга мөмкин дип исәпләнә. Нәкъ менә шул турында уйланулар мәкаләне шушы темага багышларга кирәк, дигән фикергә китерде.

Ә. Еникинең "Гөләндәм туташ хатирәсе", "Матурлык", "Әйтелмәгән васыять" – укучы тарафыннан иң яратып укыла торган әсәрләр. Язучы үзенең иҗат җимешләрендә кешенең хис – кичерешләрен, бәхетле мизгелләрен һәм хәсрәтле минутларын тел – сурәтләү чаралары ярдәмендә җиткерә. Әсәрләрдә кайгы һәм шатлык хисләре төрле чаралар ярдәмендә белдерелгән. Мисал өчен, *"Билгеле, ул балаларына бик риза, күңеленнән аларга рәхмәтен укып кына тора, әмма шулай да аларның бу соңгарак калган яхшылыклары вакыт – вакыт карчыкка аны фани дөньядан юатып озатыр өчен генә эшләнгән шикелле булып тоела, шуңа* ***йөрәге сызланып куя****, һәм* ***чыкмаган җанда өмет бар дигәндәй****, иң элек бер алласына сыенып, тыныч кына ята бирә"* [2: 24]. Күргәнебезчә, автор геройның хәсрәтен *йөрәге сызланып куя* күчерелмә мәгънәдәге гыйбарәсе аша бирә. Җөмләдә китерелгән мәкаль ирония белән бирелеп, хәсрәтнең ни дәрәҗәдә тирән булуын күрсәтә. Түбәндәге мисалларны да кайгы – хәсрәтне сурәтләүче синонимнарга кертеп карарга була: "*Шагыйрь тавышы өзелгәндәй шулай ук кинәт кенә тынып кала, башын артка чөя һәм күз төбендә аның* ***тәгәрәп төшә алмаган яшь бөртекләре күренә****"*[2: 29]. "*Атналар буе янымнан китмичә* ***кан калтырап утырган чакларында*** *ниләр уйлап, ниләр кичергәнен аның* ***саргаеп – суырылып калган йөзеннән*** *үк күреп була иде*" [2: 354]. "*Шуларны уйлагач, Акъәбигә* ***гаять авыр булып китә****, алар да, үзе дә аңа бик кызганыч булып тоела һәм ихтыярсыздан* ***кайнар яшьләре мөлдерәп агып төшә***"[2: 30]. Мисалларда китерелгән эмоциональлекне белдерүче берәмлекләр бер-берсеннән хис-кичереш дәрәҗәсенең төрлелеге белән аерылалар. Кайгы-хәсрәтнең иң югары ноктасын *чыкмаган җанда өмет бар* мәкале белдерә.

Ә. Еники әсәрләрендә күңелгә сыймаслык бәхетне чагыштыру һәм сынландыру аша укучысына җиткерә, аны герой кичергән хисләр дәрьясына алып кереп китә. Бәхет һәр кеше өчен үзгә төшенчә булып тора һәм ул сәбәбенә, урынына, вакытына карап, әдип тарафыннан төрлечә сурәтләнә. Мисал өчен, *"Аңлыйсызмы, күз алдыгызга китерә аласызмы – гүя бу зураеп ачылган сыңар күздәге өнсез карашта,* ***бер адәм затына гына түгел, бөтен җан иясенә хас ниндидер менә үзе эшләгән могҗизага таң калу һәм шуңа чиксез куану, шуның белән әйтеп бетергесез горурлану ап-***

***ачык чагылып тора иде***: *ул тапкан бит бу баланы!"*[1: 358]. *"Тик **шушы моң эчендә, томан аша караган тулы ай** төсле, Бәдретдиннең әнисе үзенең **сүзсез шатлыгы белән яктырып утыра**"* [1: 358].

М. Мәһдиев әсәрләрендәге образлар уртак максат, уртак авырлыклар, уртак сагыш белән яшиләр. Автор иҗатында кешенең күңел кичерешләрен, эмоциональ халәтен чагылдыруга зур урын бирелә. "Ут чәчәге", "Без – кырык беренче ел балалары" һәм "Кеше китә – җыры кала" әсәрләрендә ул геройларны төрле ситуацияләрдә калдырып, аларның уйларын, хис – тойгыларын укучыга җиткерә. Моңа мисал булып, *"Ләкин Зәйтүнә өчен бу көтеп тору бик бәхетле бер мизгел иде, ул **рәхәтенә чыдый алмыйча**, Асафның яңагыннан сыпырды, үзе еш – еш сулый, **үзе көлә, үзе елый да иде булса кирәк**"* [4: 491]. Бу җөмләдә язучы геройның шатлыгын антонимнар ярдәмендә сурәтли, шушы хисләрнең ни дәрәҗәдә көчле булуын *рәхәтенә чыдый алмыйча* гыйбарәсендә чагылдыра. Шушы ук юнәлешкә караган мисаллар булып, *"Юантык хатын **шат чырайлы, каушаган** кызына **сөеп карады**"* [4: 481]. *"Баязитова кайтып керүгә капчыгын чишеп газетага төргән рулетны әнисенә бирде. Сеңелләре **йөгерешеп килделәр, кочакладылар**"* [3:23].

М. Мәһдиев кайгы – хәсрәткә баткан, аннан чыгу юлын таба алмаган геройларның эмоциональ халәтен аларның тышкы портретлары аша сурәтли. Мисал өчен, *"Сәхабә **кипкән, ябыккан, саргайган**"* [3: 159]. *"Борчу-хәсрәт тормышны үзгәртте дә куйды. Аның чигәсендә **ак чәчләр** күренде"* [4: 494]. Автор китергән *кипкән, саргайган, ябыйккан* хатын образы укучыда кайгыга бирелеп, төшенкелектә гомер кичергән кеше халәтен тирәнрек күзалларга ярдәм итә. *Ак чәчләр* күп борчу-хәсрәт аша узып, өмете өзелгән мәгънәсенә ишарә ясап бирелгән. Бу хисне автор фразеологизм һәм метафора ярдәмендә дә сурәтли: *"Теге явызыңны тизрәк алып кит, кырык ел яшәгән коемнан куып чыгарды, – дип **җиде пар күзеннән яшь коя** ди..."* [3:159]. *"Иренең коточкыч гарип булып кайтуына, сугышның аларның бәхетен җимерүенә һәм дөньяның башка күп җәбер – каһәренә ачудан аның йөрәгенә күптәннән инде **кара кан урнашкан** иде"* [3: 231].

Гомумән алганда, Ә. Еники белән М. Мәһдиев иҗатында кешенең эмоциональ халәтен белдерү зур урынны алып тора. Эш барышында эмоцияләрнең фразеологик әйтелмәләр, метафора, антонимнар, мәкальләр кулланып, ирония рәвешендә, чагыштыру, сынландыру һәм тышкы портрет аша бирелүен мисаллар ярдәмендә тикшердек һәм шатлык, кайгыны чагылдыручы эмоцияләрнең синонимнар ярдәмендә бирелешен ачыкладык.

**Әдәбият**

1. Еники Ә.Н. Әйтелмәгән васыять: Повестьлар, хикәяләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. – 431 б.

2. Еники Ә.Н. Әсәрләр: 2 томда: 2 том: Повестьлар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1991. – 415 б.

3. Мәһдиев М.С. Кеше китә – җыры кала: Хикәя һәм повестьлар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1979. – 272 б.
4. Мәһдиев М.С. Сайланма әсәрләр: 3 томда: 1 том: Повестьлар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1994. – 534 б.
5. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: 3 томда: 3 том. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1981. – 832 б.

## ТАТАР МӘДӘНИЯТЕНДӘ ХАТЫН-КЫЗ СЫЙФАТЛАРЫ БИРЕЛЕШЕ

*Әсхәдуллина Г., КФУ, III курс студенты*
*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Д.Х. Хөснетдинов*

Татар халкы тормышында хатын-кызларның яшәү рәвешен, бурычларын, фикер йөртү үзенчәлекләрен ачыклау өчен, халыкның гасырлар дәвамында туплаган хәзинәсе – йола, гореф-гадәт, авыз иҗаты үрнәкләре ярдәм итә. Лингвокультурологик анализ нигезендә тел һәм мәдәниятне яшәтүче халык аңында тудырылган хатын-кыз камиллеге (идеалы) һәм тискәре яклары (антиидеалы) турындагы күзаллауларны торгыза алабыз.

*“Хатын-кыз”* концептының психологик үзенчәлекләре яссылыгына характер үзенчәлекләре, аның әхлакый сыйфатларын, интеллектуаль һәм эмоциональ үзлекләрен күз алдында тотабыз, шулай ук хатын-кыз һәм ир-ат арасындагы мөнәсәбәтләр дә искә алына.

Татар хатын-кызының төп эше элек-электән йортны карап тоту, хуҗалыкны алып бару, өй эшләрен тиешенчә эшләү булган. Шуңа бәйле рәвештә татар дөнья картинасында ялкау һәм эшчән поляр үзенчәлекләре чагылыш таба:

*Аш өенә күз салсаң, хуҗа хатынының йөзен күрерсең.*

Хатын-кызның интеллектуаль үзенчәлекләре дигәндә, аның акылы күз алдында тотыла. Татарларда *Акыллы хатын – хәзинә; Белемле кыз – бирнәле кыз* дигән мәкальләр бар.

Мәкаль һәм әйтемнәрдә хатын-кызның тискәре сыйфатлары белән бергә уңай сыйфатларыда мактап әйтелә. Аеруча елгырлык, акыллылык кебек сыйфатлар. Мәсәлән:

*Уңган хатын кар өстендә казан кайната.*

Ләкин шуны искәртергә кирәк: акыллы дигән төшенчә астында югары интеллектлы дигән мәгънә күз алдында тотылмый, ә зирәк, тугры, уйлап эш итүчән дигән мәгънәне аңларга кирәк. Ләкин патриархаль җәмгыятьтә ирләр хатын-кызның фикеренә колак салмаганнар. Бу татар дөнья сурәтендә дә, шул исәптән паремиологиясендә дә, чагылыш тапкан:

*Тавык – кош түгел, хатын – кеше түгел.*

Мәкаль һәм әйтемнәрдә хатын-кызларның уңай әхлакый сыйфатларына өстенлек бирелә. Мәсәлән, беренче чиратта хатын-кыз акыллы уңган, яхшы хуҗабикә булырга тиеш. Мәсәлән,

*Акыллы хатын – хәзинә;*

*Яхшы хатын – өй даны* кебек әйтемнәр шул хакта сөйли.

Татар халкы күзаллавында хатын-кызга хас булырга тиешле тагын бер сыйфат – әдәплелек, оялчынлык:

*Оялчан хатын – шәһәр бәясе, оялчан ир – тәкә бәясе;*

*Хатын-кызны бизәктән дә бигрәк әдәп-нәзакәт бизи һ.б.*

“Яхшы хатын” лексик-семантик төркеменә караган мәкальләрдә идеаль хатынның төп сыйфатлары билгеләнә. Алар хезмәт сөючән, иренә буйсынган, акыллы булырга тиеш:

*Акыллы хатын – хәзинә;*

*Дөнья рәхәте изге хатын белән.*

Яман, усал, оятсыз хатыннар турындагы мәкальләр ике тапкыр күбрәк:

*Алама хатын – аязлы-яктылы көн;*

*Оятсыз хатын – тозсыз аш кебек.*

Татар халык мәкальләре начар, яман хатынны бәла белән тиңлиләр, аңа түзеп торырга ярамый, хатыннарга акыл өйрәтергә, ягъни кыйнарга да өндиләр: *Хатын-кызның елга бер чәчен туздырып кыйнамасаң, башына карга оялый, ди.; Хатынны җандай ярат, кыйнап аркасын канат.*

Мәкальләрдә төрле тәкъдимнәр, нормалар бирелә, шулай ук хатын-кыз нинди булырга яки булмаска тиешлеге әйтелә. Мәсәлән,

*Хатын алганда, төсеннән бигрәк холкын тикшер;*

Татар халык мәкаль һәм әйтемнәрендә хатын-кыз холкының иң еш телгә алына торган тискәре сыйфаты булып явызлык тора. Мәсәлән,

*Яман хатын алганчы, буйдак йөр картайганчы;*

*Аяз көннең яшеннән, хатын-кызның усалыннан курык;*

Ешлыгы буенча икенче урында күп сөйләү кебек тискәре гадәтне гаепли торган мәкаль һәм әйтемнәр тора. Мәсәлән,

*Ир бер сүзле, хатын кырык сүзле;*

*Хатыннар өчен иң авыр эш – сер саклау.*

Исрафчы, уңмаган булу кебек сыйфатларны гәүдәләндергән мәкаль һәм әйтемнәр саны күп булмаса да, халык аларны кискен гаепли. Мәсәлән,

*Исрафчы хатынга патша байлыгы да җитмәс.*

Татар халкында ирдәүкә булу хатын-кызларның тискәре сыйфаты санала. Физик көч, тәртипсезлек мәкаль һәм әйтемнәрдә тәнкыйтьләнә. Мондый хатын-кызларны ирдәүкә дип тә, кыз тәкә дип тә атыйлар. Мисалларга игътибар итик:

*Ирдәүкә ни ир түгел, ни хатын түгел;*

*Ирдәүкә хатынга сакал җитмәс.*

Шунысын билгеләп үтәргә кирәк: татар халык мәкаль һәм әйтемнәреннән күренгәнчә, хатын нинди генә булмасын (яшьме – картмы, чибәрме – ямьсезме, тырышмы – ялкаумы), аңардан башка тормыш мөмкин түгел: *Хатын кеше – өй фәрештәсе.*

*Хатынсыз өй сусыз тегермән кебек.*

Татар халык мәкаль һәм әйтемнәрендә кызларның көләргә яратучанлыгы турында да әйтелә: *Кызлар бүрәнә ярыгыннан да көлә.*

*Кызлар кара сыерның борын тишегеннән көләләр.*

Күргәнебезчә, татар дөнья сурәтендә хатын-кызга төрле уңай һәм тискәре әхлакый сыйфатлар хас.

**Әдәбият**

1. Нәкый Исәнбәт. Татар халык мәкальләре. 2 том. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1963.

## ШАГЫЙРЬ ШӘХЕСЕН МӘҢГЕЛӘШТЕРҮ: ТАТАРСТАНДА ТУКАЙГА ҺӘЙКӘЛЛӘР

*Әхмәдиева Й., КФУ, II курс студенты*

*Фән. җит. – филол. фән. докт., проф. Ф.С. Сәйфулина*

Халкыбызның бөек шагыйре, татар поэзиясен төрки дөньяга танытучы шәхес – Габдулла Тукай исемен мәңгеләштерү – шагыйрьнең вафаты көненнән үк башлана. Татарстанның авыл-шәһәрләрендә, шагыйрь туган, яшәгән яки булган төбәкләрдә аның исеме белән урам, сквер, парк исемнәрен атау, музейлар ачу, картиналар язу – шушы юнәлештәге эшләрнең бер юнәлеше.

Әлеге юнәлештә башкарыла тораган эшләрнең тагын берсе – шагыйрь исеме белән бәйле булган төбәрләрдә һәйкәлләр кую белән бәйле. Шундый урыннарның берсе – Кушлавыч авылы – дөньяга татар халкының бөек улы Габдулла Тукайны биргән авыл. Ул элеккеге Казан губернасы Казан өязе Иске Мәңгәр волостенә кергән. Шагыйрьнең бронзадан эшләнгән бюсты Кушлавычта 1955 елда куела, аның скульпторы – И.А. Новоселов. Монда, шулай ук, 1976 елда Тукайга багышланган музей да ачыла [1: 23].

Казан шәһәре белән шагыйрь ятимлек язмышына тартылган чакларда ук “очраша”. Биш яше тулган җәйдә аны Казанга алып барып, асрамага бирәләр. Тукай шәһәр тормышының матур якларын күрә. Икенче тапкыр Тукайны Казанга авылдашы Бадри абзый алып килә. Казандагы бер кунакханәдә “бер-ике атна” яшәнгәннең соң Алты-биш Сапый аны Җаекка алып бара [2: 321].

Җаекта яшәгәндә Тукай Казандагы хәл-әхвәлләрдән шактый хәбәрдәр була, Казанда чыга башлаган журналлар, газеталар белән даими танышып, анда эшчәнлек алып барган кайбер затларның килешмәгән, үзенә ошамаган гамәлләрен кискен тәнкыйть иткән. Шуңа да карамастан, ул Казан турында гаять уңай фикердә. Моңа ачык дәлил – “Пар ат” шигыре.

Җаек шәһәреннән Казанга Тукай Казанның Печән базарында асрамага бирелгән ятим бала сыйфатында түгел, ә танылган шагыйрь, публицист-журналист буларак кайтып кергән. Яңадан Казанга кайткач, Тукай үзен шактый кыю тота, “Болгар” кунакханәсенә урнашуга, газеталар идарәләренә юнәлә. Казанның татар зыялылары, журналистлары, язучылары белән таныша, алар Тукайны үз даирәсенә алалар. Казан

чорында әдипнең иҗаты ә яңа биеклекләргә күтәрелә. Нәширләр аның китапларын бастырырга атлыгып торлар: 1907-1914 елларда Тукайның 33 китабы Казан матбугаларында дөнья күрә.

Г. Тукайның вафатыннан соң 45 ел үткәч, Казанның Куйбышев мәйданында, шәһәр үзәгендәге бакчада, кеше иң күп йөри торган урында һәйкәлнең беренчеләрдән булып ачылуы очраклы түгел. 1993 ел азагыннан Куйбышев мәйданы исеме үзгәртелеп, хәзерге көнгә "Тукай мәйданы" исемен йөртә. Кулына китап тотып баскан мәгърур карашлы шагыйрь һәйкәлен скульпторлар С.С. Ахунов, Л.П. Писаревский, Л.С. Кербель һәм Л.М. Павловлар эшләгән [3]. Һәйкәл кулына ачык китап тоткан Габдулла Тукайның кара лабрадориттан ясалган биек постаментка куелган бронза сыныннан гыйбарәт. Ул татар әдәбияты классикасына әврелгән әкият, поэмаларының авторы. Аның әсәрләр геройлары Татарстанның һәр кешесенә кечкенәдән таныш. Постамент квадрат нигездә урнашкан, аның дүрт кырлы аскы өлеше акрынлап сигез кырлыга күчә. Постаментның түбән өлеше татар халык орнаменты белән камаланган. Алгы өлешендә кирилл һәм гарәп алфавиты белән "Габдулла Тукай. 1886-1913" дип чокып язылган.

Г. Тукай иҗатының чәчәк аткан чоры һәм үлеме Казан шәһәрендә була. Шагыйрьгә икенче һәйкәл Казанның Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры янында куелган. Әлеге Һәйкәл скульпторы – Е.Х. Шулик. 1956 елда һәйкәлне бетоннан коялар. 2005 елда ул бронзадан ясатылып, кире үз урынына кайтарыла [4].

Татарстан Республикасы Арча районына караган Яңа Кырлай авылында яшәгән елларын Тукай үзенең автобиографик "Исемдә калганнар" повестендә язып калдыра, замандашлары истәлекләрендә дә шагыйрьнең бу төбәктәге тормышы шактый яктыртыла. Кырлай Тукай өчен "дөньяга иң элек күзе ачылган урын" буларак билгеле. Шуңа да, мәшһүр Казан артының Арча районы Яңа Кырлай авылында Габдулла Тукай әдәби-мемориаль музее алдында күренекле рәссам, скультор Бакый ага Урманчы эшләгән мәһабәт һәйкәл куела [1: 6].

1991 елда Татарстанның Түбән Кама шәһәрендә Г. Тукай урамындагы бакчада (ул чакта урам Кояшлы дип аталган) татар шагыйренә һәйкәл ачыла. Һәйкәлнең авторы – күренекле сынчы Б. Урманче, архитекторы – Ф. Ханов.

Шагыйрь иҗатын мәңгеләштерү максатыннан Г. Тукайга багышланган тагын бер һәйкәл 1992 елда Түбән Кама Үзәк район күппрофильле хастаханәсе янында куела. Ул Габдулла Тукайның Арча районы Кырлай авылындагы мемориаль музей комплексында сынчы Б. Урманче проекты буенча 1957 елның 20 октябрендә ачылган һәм 2006 елда бронзадан яңартылган күпләргә таныш һәйкәле рәвешендә эшләнгән.

Шагыйрьнең 125 еллык юбилее уңаеннан Татарстанда тагын бер һәйкәл ачыла: ул Яр Чаллының Яңа шәһәрендәге Тукай скверында Урнаштырылган. 2012 елдан башлап, хөкүмәт бүләкләренә лаек булган шәхесләргә дәүләт бүләкләре әлеге һәйкәл янында тапшырыла. Проектның авторы – скульптор Владимир Демченко, һәйкәлне сынчы Илдар Ханов иҗатына таянып ясаган. Автор шагыйрьне ялгыз фигура рәвешендә түгел, ә үзе язган әдәби әсәрләре каһарманнары әйләнәсендә итеп күрсәткән. Имән агачы белән тоташкан Шүрәле образына зур урын бирелгән.

Тагын бер һәйкәл 2014 елның 19 декабрьдә Алабугада ачыла. Шул рәвешле алабугалылар да һәйкәл ачып, бөек шагыйрьнең истәлекле мирасына хөрмәтле булуларын раслады. Бронза һәйкәлнең биеклеге – 3 метр. Һәйкәлнең авторы – Мәскәү сынчысы В. Демченко.

Татарстандагы Тукай һәйкәлләре – татар халкының мәдәниятен, әдәбият-сәнгатен берләштерүче символ, Федераль дәрәҗәдәге мәдәни мирас объекты.

**Әдәбият**

1. Антонова Б.Ф., Вәлиева Л.Г. Габдулла Тукайның әдәби-мемориаль музее. – К.: Татар. кит. нәшр., 1984. – 64 б.

2. Габдулла Тукай. Энциклопедия. – Казан: Г. Ибраһимов ис. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2016. – 864 б.

## ФЭНТЕЗИ ӘСӘРЛӘРЕНЕҢ ТАТАР ҺӘМ ТӨРЕК ТӘРҖЕМӘЛӘРЕНДӘ РЕАЛИЯЛӘР БИРЕЛЕШЕ

*Әхмәтгәрәева Г., КФУ, II курс магистранты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. К.С. Фәтхуллова*

Эквивалентсыз лексиканы тәрҗемә итү – тәрҗемә теориясенең иң актуаль мәсьәләләренең берсе. Аның кысаларында *реалияләр* дә өйрәнелә. Реалияләр – ул теге яки бу ил тормышын, гореф-гадәтләрен, йолаларын, гомумән, милли үзенчәлекләрен чагылдырган берәмлекләр [1: 25].

Реалияләр, чынбарлыкны гына түгел, автор тарафыннан уйлап табылган дөнья күренешләрен дә атый. Аеруча бу *фэнтези жанры* әсәрләрендә күзәтелә, чөнки аларның төп дифференциаль сыйфаты булып тылсымлы дөнья тора. Аны ышандырырлык итәр өчен, авторлар төрле реалияләр уйлап чыгара.

1997 нче елны Джоан Роулингның фэнтези жанрына караган «Harry Potter and The Philosopher's Stone» китабы дөнья күрә. Ул британ реалияләреннән тыш, уйлап чыгарылган дөнья реалияләре исәбенә дә баетыла. Аларны Джоан Роулингның татар һәм төрек тәрҗемәләре нигезендә карап узыйк. Моның өчен И.С.Алексееваның реалияләр классификациясен [2: 181] һәм Р.А.Юсуповның реалияләрне тәрҗемә итү ысулларын кулланыйк [3: 74].

1. Географик реалияләр:

- Физик география терминнары.

Чынбарлыкта булган географик реалияләр кирилл әлифбалы татар теленә транслитерацияләнә, ә латин әлифбалы төрек теленә үзгәрмичә күчерелә: Kent – Кент, Kent; Yorkshire – Йоркшир, Yorkshire; Bristol – Бристоль, Bristol; London – Лондон, London; King's Cross – Кингс Кросс, King's Cross вокзалы һ.б. Уйлап чыгарылган географик реалияләр өлешчә калькалаштырыла: Privet Drive – Бүрекүз урамы, Privet Drive; Diagon Alley – Кыек тыкрык, Diagon Yolu; The Leaky Cauldron – Тишек казан, Зatlak Kazan; Forbidden Forest – Тыелган урман, Yasak Orman һ.б.

- Эндемика (хайван, кош-корт, үсемлек төрләре) терминнары.

Төрки телләргә, нигездә, транслитерацияләнә: Hedwig ['hədwɪg] – Һедвиг, Hedwig, Scabbers ['skҗbərs] – Скабберс, Scabbers һ.б. Ләкин кайберләре татар теленә калькалаштырыла: Fluffy – Мамыккай һ.б.

2. Этнографик реалияләр:

- Кием-салым исемнәре.

Монда ике сүзне – robe һәм cloak сүзләрен аерып күрсәтергә кирәк: robe – мантия, cьbbe; cloak – плащ, pelerin. Тылсымлы кием-салым мәгънәсендә калькалаштырыла: Invisibility Cloak – Күренмәс мантия, Gцrьnmezlik pelerini.

- Йолалар, ырымнар, уеннар.

Әсәрдә шушы тылсымлы дөньяга гына хас спорт төре тасвирлана. Ул оча торган туплар белән себеркеләргә атланып уйнала. Аның исеме – Quidditch: Квиддич, Quidditch. Туплар татар теленә транслитерацияләнә, төрек телендә шулай ук кала: Quaffle – Квоффл, Quaffle; Bludger – Бладжер, Bludger; Snitch – Снитч, Snitch. Уенчылар төре калькалаштырыла: Chaser – Аучы, Kovalayici; Keeper – Сакчы, Tutucu; Beater – Бәрүче, Vurucu; Seeker – Эзләүче, Arayici.

- Мифология һәм культлар.

Фэнтези жанрына хас булганча, Джоан Роулинг әсәрләре дә мифологиягә нигезләнә, биредә төрле мифологик затлар катнаша. Алар түбәндәгечә тәрҗемә ителә: goblin – гоблин, goblin; dragon – аждаһа, dragon; phoenix – феникс, anka; troll – тролль, Ifrit; unicorn – сыңармөгез, tek boynuzlu at һ.б.

- Үлчәү һәм акча берәмлекләре.

Тылсымлы акча татар теленә транслитерацияләнә, төреккә – үзгәрешсез күчерелә: galleon – галлеон, galleon; sickle – сикль, sickle; knut – кнат, knut.

3. Иҗтимагый-сәяси реалияләр.

Оешма атамалары: Ministry of Magic – Тылсым министрлыгы, Sihir Bakanlığı; мәгълүмат чаралары: Daily Prophet – Көндәлек пәйгамбәр, Gelecek Postasi (Daily News, Daily Mail кебек инглиз һәм американ газеталарына ишарә); дәреслекләр: «Great Wizarding Events of the Twentieth Century» – «Егерменче гасырның бөек тылсым вакыйгалары», «Yirminci Yьzyilin Bьyьk Bьyьсьlьk Olaylan»; Һогвартс уку йорты реалияләре: The

Great Hall – Олы Зал, Вьуьk Salon; The Sorting Ceremony – Бүлү тантанасы, Sesme Tцreni калькалаштырыла.

Биредә тылсым дөньясына караган төрле предмет һәм күренешләрне аңлатып үтәргә кирәк. Мәсәлән, The mirror of erised – Рәлтемө көзгесе, Kelid Aynasi. Әлеге көзге кешенең иң ихлас һәм иң көчле теләген күрсәтә. Атамасы, көзгедә чагылган кебек, кире тәртиптә төзелә: desire – өметләр, delik.

Тылсымлы ризык атамалары да кызык: Bettie Bott's Every Flavor Beans – Берти Боттның Төрле Тәмдәге Борчаклары, Bertie Botts'un Bin Bir Зesit Fasulye; Chocolate Frogs – Шоколадлы бакалар, Зikolatali Kurbaga; Pumpkin Pasties – Кабак бәлешләре, Balkabagi Pogazasi h.б. Соңгысы аеруча игътибарга лаек: инглизләрнең пасти дигәне татар телендә – бәлеш, ә төрек телендә погача дип бирелә. Алар барысы да камырдан ясалган эчлекле милли аш-суы булып тора, ләкин үзгә сыйфатларга ия. Башка халык ризыгы тәрҗемә теле вәкиленә үз ризыгы аша аңлатыла.

Gallopin' Gorgons гыйбарәсен дә карап узыйк. Тылсымчылар аны кинәт бер хәл килеп чыкканда куллана. Борынгы грек мифологиясендә горгоннар – карашлары белән ташка әйләндергән елан чәчле хатын-кызлар. Тәрҗемәдә бу гыйбарә Горгона катыргыры һәм Vay canina дип бирелә.

Димәк, транслитерация ысулы күбрәк татар теленә тәрҗемә иткәндә кулланыла. Бу очракта реалия мәгънәсе бирелми, ул чит тел берәмлеге итеп кабул ителә. Латин элифбасыннан файдаланган төрек теле күп кенә реалияләрне үзгәрешсез кабул итә. Һәр ике телдә дә калькалаштыру очраклары да күзәтелә.

**Әдәбият**

1. Набиуллина Г.А. Перевод художественного текста: конпект лекций. – Казань: КФУ, 2014. – С. 25.

2. Алексеева И.С. Введение в переводоведение: Учеб. пособие для студ. филол. и лингв. фак. высш. учеб. заведений. – СПб.: СПбГУ; М.: Академия, 2004. – 181 с.

3. Юсупов Р.А. Тәрҗемә һәм сөйләм культурасы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. – 74 б.

## ОЛУГ ШӘХЕС – РӘШИТ РӘХМӘТИ АРАТ

*Әхсәнова Г., КФУ, I курс магистранты*

*Фән. җит. – филол. фән. докт., проф. Ә.Ш. Юсупова*

Истанбул университеты профессоры, Төркиянең тарихи-чагыштырмалы төрек тел белеме мәктәбенә нигез салучы, уйгыр-карахани кебек борынгы төрки язмалар өлкәсендә халыкара танылган белгеч булган Рәшит Рәхмәти Арат 1900 елның 15 нче маенда Татарстанның Әтнә районы Иске Әҗем авылында мөдәррис Исмәт гаиләсендә дөньяга килә. Мәктәпне тәмамлаганнан соң абыйсы белән Казакстанның Кызылъяр (Петропавел) шәһәренә китә, анда төрек-татар җәдит мәктәбендә һәм урыс гимназиясендә белем ала.

Нәкъ шул вакытларда комуннистлар режимының көчәюен булдырмас өчен, баш күтәргән адмирал Колчак армиясенә мәктәпләрдән яшьләр алынган. Шул уңайдан Рәшит Рәхмәти хәрби өйрәнү курсларына, аннан сугышка җибәрелә. Колчак армиясе җиңелеп, таралгач, Рәшит Рәхмәти яраланган хәлдә Манчжуриянең Харбин шәһәренә китә. Хәрбин шәһәрендә татар гаиләләре, үз мәктәпләре, төрле яклардан килгән мөһәҗирләр җәмгыяте дә була. Шәһәрдә Казан төрекләре колониясе мәктәбендә эшли торган мәдәни хәрәкәт эшендә актив катнаша. Аннан алданрак килеп җиткән Хөсәен Әбдүш белән бергә «Ерак Шәрык» дигән журнал чыгара башлыйлар һәм бу журнал 1924 нче елда атналык газетасына әверелә, 1925 нче елның ахырына кадәр чыга. 1922 нче елның 28 нче маеннан, ул дуслары белән берлектә «Мең ел» дигән газета чыгара. Рәшит Рәхмәти бу журнал һәм газеталарда псивдонимнары белән генә әдәби һәм публицистик хезмәтләр бастырган.

1922 нче елда югары белем алыр өчен, Германиягә китәргә карар бирә. Төрле җәмгыяви авырлыклар эчендә кайнаган Р.Рәхмәти, фән өлкәсендә бөтен көчен һәм акылын юнәлтә. 1923 нче елның язында Берлин университетында фәлсәфә факультетының тел-әдәбият бүлегендә 5 ел белем ала һәм шул вакыт эчендә мәшһүр тюрколог профессор Билли Банг-Каупның яраткан, тырыш укучысы, соңрак аның ассистенты була.

1928 нче елда Берлинда Гаяз Исхакый җитәкчелгендә «Яңа милли юл» журналы чыга башлый, Рәшит Арат үзенең мәкаләләрен һәм күп кенә шигырьләрен М. Х. Ф, Гали, Гали Биктимер, Шагыйрь Йосыф имзалары белән яки имзасын язып чыгара. 1933 нче елга кадәр шәрык телләре мәктәбендә төньяк төрекләрнең тел, әдәбият һәм тарихы буенча доцент булып эшләгән, шулай ук академия нәшрияте эшендә актив катнашкан һәм гыйльми хезмәтләрен чыгара башлаган.

1933 нче елда Рәшит Аратны Төркиягә чакыралар һәм ул Истанбул университетының төрек теле һәм әдәбияты кафедрасында профессор итеп сайлана. Бу эшне 18 ел дәвамында алып бара. 1951 нче елда Истанбул университеты каршындагы төрки телле халыклар институтының мөдире итеп сайлаганнар.

1961 нче елда Анкарада Төрек мәдәниятен тикшерү институты ачыла, җитәкчесе Әхмәт Тимер була. Татарлардан чыккан галим буларак, ул Рәшит Рәхмәтине үз янына эшләргә тарткан. Бу еларда Р.Рәхмәти бик күп хезмәтләр язган һәм алар «Төрек мәдәни тикшеренүләре» дип аталган журналга басылып барганнар. Үзенең сонгы көненә кадәр шушы институтта эшләгән һәм бай мирас калдырган.

Халыкара танылып, яңа гильми эзләнүләр белән кайнаган 64 яшлек Р. Рәхмәтинең сәламәтлеге какшый башлый. Шулай итеп, татар зыялыларының бер вәкиле Рәшит Рәхмәти, туган ягы Казаннан китеп,

дөнья гизгәннән соң Европада беркадәр яшәп алгач, үзенең ватаны итеп кабул иткән Төркиядә 1964 нче елның 29 нчы ноябрендә вафат була.

Рәшит Арат Төркия Җөмһүриятендә тюркологик тикшеренүләрне оештыруда зур роль уйный. Тюркология өлкәсендә Рәшит Аратның абруе гадәттән тыш югары була. Төрек мәдәниятен фәнни тикшереп өйрәнү институты галимнәре аның истәлеге итеп, 1966 нчы елда Анкарада «Рәшит Рәхмәти Арат өчен» дигән 454 битлек китап әзерләп бастыралар. Бу китапта аның 222 хезмәте һәм басмага әзерләнеп тә үзе исән чакта басылып өлгермәгән алты язмасы, галимнәр Мөхәммәт Әргин белән Әхмәт Тимер тарафыннан системалаштырылып бирелә.

Р. Рәхмәти Бөтен томышы һәм язган әсәрләре белән төрки халыклар тарихында тирән эз калдырган шәхесләрдән берсе.

Төркиядә яшәгән елларында Р. Рәхмәти фәнни эшчәнлек белән бик актив шөгыльләнә. 30 елга якын гомерен XI гасыр истәлеге булган «Кутадгу билиг» әсәрен өйрәнүгә багышлый. Эзләнү-тикшеренүләрен ул 4 китап итеп хәзерли. Әлеге эшендә беренче китап – текст һәм транскрипция, икенчесендә – әсәрнең тәрҗемәсе буларак, 1947 һәм 1959 нчы елларда басылып чыга. Өченче китап, шактый вакыт үткәч, 1979 нчы елда басыла, ә дүртенче китапта аңлатма –шәрехләүне үз эченә алган дигән фараз бар, әмма китап басылганмы юкмы икәне билгесез.

«Истанбул энциклопедиясе» Төркиядә ике зур тираж белән нәшер ителгән. Р. Рәхмәти бу эштә үзеннән дә өлеш кертә, ул чыгаруда башлап йөрүче, аның мөхәрирләренең берсе була. Әлеге зур күләмле хезмәттә, аның утыздан артык фәнни мәкаләсе кергән.

Галим махсус белем алган тарихчы булмаса да, илдә тарихи хезмәтләрдә ихтыяҗ зурлыгын, бу өлкәдә тикшеренүләр азлыгын белеп эшләгән. Аның гомумтөрки мәсьәләләрне яктырткан хезмәтләре дә байтак: «Тюркологиянең гомуми проблемалары», «Төрки телләрнең классификациясе», «Көнчыгыш Төркстан илләре һәм халыклары» һ.б.

Татар халкының күренекле вәкиле , 20нче йөз башы тарихи-сәяси давыллар чорында туып үскән Р. Рәхмәти мәңгелек хезмәтләре белән Төркия җөмһүрияте университеты тарихында һәм тюркология дөньясында күренекле урынын алып тора.

**Әдәбият**

1. Mustafa Ц., Professor, Dr. Rashid Rakhmati Arat, Journal Tatarica // Kazanskiy Federal’nıy Universitet. – 2015. – №4. – S. 189-194.

2. Mustafa Ц., Tariho-Karşılaştırmalı Filoloji ve Reşid Rahmeti Arat. – Prof. Dr. Talât Tekin Hatıra Kitabı – İstanbul, 2017. – S. 763-778.

3. Зәкиев М.З., Мәхмүтов Х.Ш., Надиров И.Н., Хисамова Н.Ш, Рәхимова А.Р. XX Gasırnın kürenekle tyurkologı Rəşit Rəxməti Arat – Казань: Изд-во “Мастер Лайн”, 2001. – Б. 19-42.

# ЧЫҢГЫЗ АЙТМАТОВ ӘСӘРЛӘРЕНЕҢ ТАТАРЧАГА ТӘРҖЕМӘ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

*Бариева А., КФУ, IV курс студенты*
*Фән. җит. – фил. фән. докт., проф. Ф.С. Сәйфулина*

Совет, кыргыз әдәбияты классигы Чыңгыз Айтматовның иҗаты – уникаль күренеш. Рус телендә язып та, әсәрләрендә кыргыз халкының милли үзенчәлекләрен гәүдәләндергән әдипне рус телендә иҗат итүче кыргыз язучысы дип атарга тулы җирлек бар. Ч.Айтматов әсәрләренең рус телле булулары Совет дәүләтендә рус теленең глобальрәк, дәүләт дәрәҗәсендә таралган булуы белән аңлатыла. Әмма үз халкының мәдәнияте өчен башлыча ят булган телдә дә әдип кыргыз халкының милли ядкярләрен тудыра алган. Айтматов әсәрләрендә кыргыз менталитеты, кыргыз халкының гореф-гадәтләре, йолалары, дөньяга карашлары, гади тормыш эскизлары, фәлсәфәсе тулысы белән чагылыш таба дип әйтергә мөмкин.

Әсәрләренең үз вакытында ук йөзләрчә телләргә тәрҗемә ителгән булуына күрә, Ч. Айтматов иҗаты географик чикләрне кичеп, чын мәгънәсендә дөньякүләм иҗат булып танылa. Шушындый глобальлектән татар мәдәнияте дә читтә калмый – Ч. Айтматовның шәхесе генә түгел, иҗаты да татар укучысына якын булып китә, чөнки аларда татар күңеленә якын аһәңлелек, моң, миллилек төсмерләре бар.

Ч. Айтматовның татарчага тәрҗемә ителгән әсәрләрен аерым-аерым әдәби кыйммәтләре булган мөстәкыйль иҗади берәмлекләр дип карарга мөмкин. Әлеге мәкаләдә без язучының юбилее уңаеннан 2018 елда туплап чыгарылган «Сайланма әсәрләр»дәге [1: 4] тәрҗемә әсәрләрдән файдаландык. Әлеге җыентыкта әдипнең 5 повесте һәм 1 романы урын алган. Шулардан, “Бер көн – бер гомер” (“И дольше века длится день”) романы – Рим Шириязданов, “Дөя күзе” (“Верблюжий глаз”), “Анам кыры” (“Материнское поле”) һәм “Бәхил бул, Гөлсары” (“Прощай, Гульсары”) повестьлары – Яхъя Халитов, “Җәмилә” (“Джамиля”) повесте – Миркасыйм Госманов һәм “Чыңгызханның ак болыты” (“Белое облако Чингисхана”, татар телендә беренче тапкыр бирелә) повесть Мөдәррис Вәлиев тарафыннан тәрҗемә ителгән.

Тәрҗемәләрнең сыйфатлары төрле, әмма тәрҗемәчеләрнең берсе дә турыдан-туры тәрҗемә белән шөгыльләнми, текстларга иҗади якын килергә тырыша. Мәсәлән, Рим Шириязданов тәрҗемәгә һичшиксез иҗади якын килгән. Әйтик, тимер юл будкасының тасвирына ул “ап-ак итеп акшарланган” дигән сүз өсти. Вак деталь кебек, әмма бу әйләнә-тирә сурәтен баета. Кыргыз теленең үзенчәлекле яңгырашын саклау өчен автор *хатын, хәләл җефет* мәгънәсен белдергән *аял* сүзен текстта калдыра да, аңлатмасын астөшермәдә бирә. Шул рәвештә, татар телендәге

тәрҗемәләрдә дә әсәрләрнең структур-композицион төзелеше генә түгел, кардәш кыргыз теленең яңгырашы да сакланып калган.

Тәрҗемәләрдә кайбер очракларда, киресенчә, идея-мәгънәви яктан оригиналны үзгәрткән урыннар да бар. Ч. Айтматовның «Ана кыры» (Я. Халитов тәрҗемәсендә ул «Анам кыры» дип атала) кыргыз телендә иҗат ителгән. Әмма Я. Халитов тәрҗемә вакытында рус текстына таянып эш итә. «Анам кыры» әсәре тәрҗемәләренең гомуми кимчелеге исемен тәрҗемә иткәндә үк төгәлләшә: оригиналда повесть «Саманчы жолу» («Саманчы юлы») дип атала. Әсәрнең мәгънәсе салынган исем тәрҗемә вариантларда үзгәртелеп «Материнское поле», «Анам кыры» дигән вариантта тәкъдим ителә.

Кыргыз телендәге сүзләр белән тәрҗемәчеләр төрлечә эш итә: аерым берләре тулысынча татар теле чаралары белән белдерелеп килсә, башкалары чыганак телдәге төшенчәне калдырган. Ялгызлык исемнәренең нигездә кыргыз телендәгечә вариантлары кулланылган – бу тәрҗемә әсәрләренең аһәңлеген саклап калып, аутентиклыгын, кыйммәтен арттыра. Мисал өчен: *Сильный электрический свет в железнодорожной будке вдруг резко обнаружил глубокие и никогда не исчезавшие уже морщины на синюшно потемневших щеках Укубалы* («И дольше века длится день») [1: 4] / *Ап-ак итеп акшарланган кечкенә будкадагы көчле электр яктысында Үкүбаланың каралып күгәргән битендә югалмаслык булып уелган сырлар аерымачык күренә.* (“Бер көн – бер гомер”, Р.Шириязданов тәрҗемәсе) [1: 9].

Рус транслитерациясендә бирелгән ялгызлык исемнәренең (Едигей, Укубалы) тәрҗемәче татарча вариатларын бирә (Идегәй, Үкүбала).

Чыңгыз Айтматов милли проблемаларны кискен күтәрү өчен мифлаштыру алымына еш мөрәҗәгать иткән [2: 82]. Мифологик катлаулар әсәрләрдә, нигездә, үзгәрешсез сакланып калган. Путь саманщика – Саламчы юлы дип кыргызлар Киек каз юлын (Млечный путь) атыйлар. Я.Халитов, тәҗрибәле тәрҗемәче буларак, әлеге төшенчә белән оста эш итә: *И я распрямилась, подняла голову, глянула на небо – и в груди что-то дрогнуло: высоко среди ясных звезд, через весь небосклон, как тогда, широкой серебристой полосой простиралась Дорога Соломщика. И мне опять почудилось, что и в самом деле кто-то только что прошел там с огромной охапкой соломы нового урожая и растряс ее по пути. Там, наверху, золотистые соломинки, ость и мякина шевельнулись, будто от прикосновения ветра. Можно было даже разглядеть просыпавшиеся вместе с мякиной зерна.* (“Материнское поле”) [1: 562] / *Башымны күтәреп күккә карадым, йөрәгем шунда нигәдер тилпенеп куйды: теге вакыттагы шикелле, биектә-биектә, җемелдәшеп янган йолдызлар арасыннан күк йөзе буйлап киң көмеш тасма сыман Саламчы юлы сузылган иде. Ул вакыттагы кебек, менә хәзер дә кемдер яңа гына сугылган бер кочак бодай саламын күтәргән дә шуны коя-чәчә узып киткәндер кебек тоелды. Шунда*

*күктә, җил исеп, алтын-сары саламнары, кибәк һәм кылчыкларны селкеткәләп киткән сыман булды. Кибәк белән бергә коелган бөртекләр дә күренәдер кебек иде.* (“Анам кыры”, Я.Халитов тәрҗемәсе) [1: 451].

Татарча тәрҗемәдә Я.Халитов исемен үзгәрткәндә югала башлаган мифологик катлауны текст тукымасында атамаларны үзгәрешсез кулланып саклап кала.

**Әдәбият**

1. Айтматов Ч.Т. Сайланма әсәрләр: роман, повестьлар – Казан: Татар. кит. нәшр., 2018. – 575 б.

2. Миңнуллин К.М. XX гасырның икенче яртысы татар әдәбиятын өйрәнү контекстында Чыңгыз Айтматов иҗаты // Фәнни Татарстан. – 2018. – №4. – Б. 79-82.

## ТАТАР ХАЛЫК СЫНАМЫШЛАРЫНДА КУЛЛАНЫЛГАН ТЕЗМӘ СҮЗЛӘРНЕҢ ЯСАЛЫШ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

*Баһавиева Ч., КФУ, III курс студенты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Р.Р. Сәлахова*

Халык авыз иҗаты – әдәби теленең нигезен, рухи байлыгын тәшкил итүче төп көч. Фольклористиканың фән буларак формалашуы аерым халыкларның авыз иҗаты үрнәкләрен язмада теркәү һәм җыю эшчәнлегеннән башлана. Татар фольклорын фән буларак өйрәнә башлау, аның үсеп китүе Октябрь революциясеннән соң киң таралыш ала, фольклор әсәрләре телен аерым өйрәнү XX гасыр ахырында гына гамәлгә кертелә.

Фольклор жанрларыннан безнең игътибарны җәлеп иткәне – сынамышлар. Сынамыш – табигать күренешләренә, хайван һәм кошларның гамәлләренә карап, һава торышын фаразлауга корылган, халык иҗатының борынгы жанрларыннан берсе. Сынамышның төп максаты, вазыйфасы – киләчәкне хәбәр итү. Аларга хас алдан күрүчәнлек, беренче чиратта, халыкның гасырлардан килгән көндәлек тәҗрибәсенә бәйле.

Сынамышлар гади охшатуга нигезләнгән әйтемнәр генә түгел, ә фәнни яктан да исбатлый алырлык күзәтү буларак бәяләнергә хаклы [1: 43]. Аларның һәркайсысының үз логик, рациональ аңлатуы бар: һәр сынамышны физика, химия, биология кануннарына нигезләнеп, аңлату мөмкин.

Сынамышлар тел белеме белгечләре һәм галимнәрнең игътибарын җәлеп итә торган жанр. Һәр сынамышның нигезе – ул капма-каршы куюю. Шуңа нисбәтле сынамышлар теле дә башка халык авыз иҗаты әсәрләреннән аермалы буларак, үзенә генә хас стильгә ия [4: 132]. Сынамышларның нигезендә яткан гыйлем халыкның характерын һәм аңын гына түгел, аның теленең төзелеш үзенчәлекләрен дә яхшырак аңларга мөмкинлек бирә.

Фольклористика телен өйрәнү – ул халыкның тел тарихын өйрәнүгә бәрабәр, чөнки халык авыз иҗаты әсәрләре борынгы заманнарда иҗат ителгән һәм аларда шул чорга хас булган аерым бер урынлыкта яшәүче төркемнең тел үзенчәлекләре сакланып калган. Шундый үзенчәлеккә ия

булган тел берәмлекләренең берсе – тезмә сүзләр. Сынамышларда тезмә сүзләрнең бирелеше дә аерым игътибар итүне сорый, чөнки башка әдәби әсәрләрдә мондый төр тезмә сүзләр кулланылышы очрамый диярлек.

Тезмә сүзләр – сүзләр кушылу ысулы белән ясалган сүзләр. Икенче төрле әлеге ысулны синтаксик юл белән сүз ясалышы дип тә атыйлар. Татар телендәге күпчелек тезмә сүзләр үзләренең төзелеше буенча синтаксик берәмлек булган төрле типтагы сүзтезмә модельләренә туры киләләр.

Тезмә сүзләрнең ясалыш үзенчәлекләрен тикшерү өчен без Ф.Ә. Ганиев бүленешенә нигезләндек, һәм компонентлары кайсы сүз төркеменә каравыннан чыгып, аларны ясалыш модельләре буенча төркемнәргә бүлдек.

1. Исем + тартымлы исем тибы:

*1) Әгәр **елга суы** боз өстенә чыкса, көн җылытыр* [2: 31].

*2) **Яз көне тамчы бозлары** озын булса, сабан ашлыгы озын булыр* [2:31].

*3) **Суган кабыгы** калын булса, кыш салкын килә* [2:31].

*4) **Чана юлы** соңга калса, ашлык уңар* [2: 33].

*5) **Май ае** салкын булса, игенгә туклык* [2: 32].

Иң күп мисал әлеге типка керде. Алда әйтеп үтелгәнчә, тезмә сүзләр бай мәгънәви төрлелеккә ия, ягъни аларда төрле мәгънә мөнәсәбәтләре чагылыш таба. ***Яз көне, май ае*** кебек сүзләрнең беренче компонентлары вакыт мәгънәсен тәгъбир итәләр. Сынамышлар табигать күренешләре белән турыдан-туры бәйле, шуңа күрә ел фасылларын һәм вакыт төшенчәләрен барлык мәгънә тулылыгы белән белдерү биредә мөһим роль уйный. Сынамышларда урын мәгънәсен белдерә торган сүзләр дә еш очрый. Бирегә ***чана юлы*** мисалын кертеп карарга була. Тикшерү барышында мисаллардан табылган тагын бер кызыклы төркем – кисәкнең бөтенен белдерүче сүзләр. Боларга ***тамчы бозлары, суган кабыгы, елга суы*** кебек сүзләрне кертергә була.

2. Фигыль + фигыль тибы:

*1) Әгәр кар вак кына бөртекле, сирәк кенә төшкәләсә, көннәр **суытып җибәрер*** [2: 31].

*2) Мартта кар тиз **эреп бетсә**, игенгә күп файда* [2: 33].

*3) Сентябрьдә кырмыскалар үлән өстендә **чабышып йөрсә**, кар тирән булып ятар* [3: 31].

*4) Өченче сентябрьдә каен яфраклары **саргаеп бетсә**, әбиләр чуагы озак булыр, салкыннар соң килер* [3:35].

*5) Өй тирәсендә карлыгач **очып йөрсә**, һава начар булыр* [3: 31].

Биредә фигыльләр кинәтлек төсмере белән башланып киткән кискен эш-хәрәкәтне, эш-хәрәкәтнең тулысынча тәмамлануын һәм өзлексез, субъект өчен чагыштырмача даими булган эш-хәрәкәтне белдерәләр.

3. Фигыль түгел + фигыль тибы:

*1) Көннәр берничә көн рәттән бик эссе торса, озакламый* ***ялт-йолт итеп*** *арыш камчылар* [3: 31].

*2) Озынборыннар яздан ук* ***гөж килеп*** *югары болгансалар, солы бик уңар* [3: 29].

*3) Үрдәкләр суда* ***чупыр-чупыр килеп*** *кагынып кычкырсалар – яңгырга. Әгәр суда шыпырт кына торсалар, яшен булыр* [3: 33].

*4) Торна кар барында беренче* ***хәбәр бирсә****, тары, борчак уңар* [3: 31].

Әлеге модельдә төзелгән тезмә фигыльләр, эш-хәлнең күп мәртәбә кабатлануын һәм эш-хәрәкәтне башкаруны тәгъбир итәләр.

Шулай итеп, татар халык сынамышларында кулланылган тезмә сүзләр күренешләрне конкретлаштырып киләләр, алар турында төгәл күзаллаулар булдырырга ярдәм итәләр. Алар вакыт, урын һәм башка мәгънә мөнәсәбәтләрен ачыклап килергә, шулай ук эш-хәрәкәтнең төрле төсмерләрен тулы итеп бирергә сәләтле тел берәмлекләре булып торалар.

**Әдәбият**

1. Гыйльманов Г. Татар мифлары: иярләр, ышанулар, ырымнар, фаллар, сынамышлар, йолалар. – Казан: Татар. китап нәшр., 1996. – 388 б.

2. Миңнуллин К., Урманче Ф. Татар халык иҗаты: Хрестоматия. – Казан: Мәгариф, 2004. – 479 б.

3. Мәхмүтов Х. Ш. Халык афоризмнары. Беренче китап. – Казан: Мәгариф, 2002. – 143 б.

4. Урманче Ф. И. Татар мифологиясе. Энциклопедик сүзлек: 3 томда: 3 т. (С – Я ). – Казан: Татар. китап нәшр., 2011. – 199 б.

5. Татар грамматикасы. Өч томда. Т.1. – М: Инсан; Казан: Фикер, 1998. – 512 б.

## СРАВНИТЕЛЬНЫЕ КОНСТРУКЦИИ В ФОЛЬКЛОРНЫХ ТЕКСТАХ
(на материале татарских и русских загадок)

*Болгарова А., КФУ, студент II курса*

*Науч. рук. – канд. филол. наук, доц. Р.М. Болгарова*

Являясь коллективным произведением, загадка может рассматриваться как единица, формирующаяся в сознании представителей целой лингвокультурной общности и отражающая национальную специфику видения мира. С течением времени, функциональная природа загадки изменилась, однако популярности она не утратила.

Н.Г. Титова определяет загадку как «языковую единицу, используемую в актах коммуникации с целью общения, обмена информацией, проверки сообразительности, кодирования табуированной лексики, а также праздичного развлечения читающего/слушающего. Загадка реализуется двумя активными исполнителями, один из которых осуществляет иносказательное описание объекта, его параметров или функций, посредством введения в текст семантически неоднозначных конструкций (метафоры, игры слов, парадокса, каламбурного алогизма и т.п.), а второй – угадывает зашифрованный в иносказательном описании объект» [3: 319].

Загадки по содержанию делят на следующие группы: 1) человек, его деятельность и повседневная жизнь; 2) природный мир (стихийные объекты и силы природы, фауна и флора); 3) предметы и понятия материальной культуры; 4) предметы и понятия духовной культуры; 5) вселенная, ее объекты и явления. В шестую группу условно можно объединить арифметические загадки. Немало загадок, использующих в текстах описание национальной одежды, блюд и украшений. В них наиболее ярко проявляются особенности характера того или иного народа. Изменения в жизни народа также находят отражение в фольклорных текстах. Поэтому реалии, отражающие технические достижения, как автомобиль, самолет, поезд, телефон, фотоаппарат, радиоприемник, магнитофон, телевизор, ракета, спутник Земли используются в загадках более позднего периода.

В загадках часто используются различные изобразительные средства: сравнения, аллегория, перифраз и т.п. Ответы на загадки связаны с человеком, материальной и духовной культурой. Поэтому изучение загадок дает представление о татарском и русском народах: ремеслах, семейной жизни, одежде, пище и питье, вооружении и другой технике, средствах транспортной связи, в общем, духовной и материальной культуре. В загадках чаще, чем в других фольклорных произведениях, используются сравнения, так как в большинстве случаев загадка строится на сопоставлении. Рассмотрим загадки татарского и русского языков и объекты, используемые в них.

В первую группу мы объединили сравнения, связанные с природой: *Аш ашамас, Кара су эчәр, Дөньяда кош кебек очар, Күңелләргә нур чәчәр (Язу); Аягы юк, кулы юк, Сөйләшергә теле юк, Кояш кебек нуры юк, Күрергә күзе юк, Һич җитмәгән җире юк (Җил)* [2]; *Я молча смотрю на всех, И смотрят все на меня. Веселые видят смех, С печальными плачу я. Глубокое, как река, Я дома, на вашей стене. Увидит старик - старика, Ребенок... (Зеркало); Зеленые мы, как трава, Наша песенка: "Ква-ква". (Лягушка)* [1]. Данные сравнительные конструкции часто встречаются в татарских и русских загадках.

Во вторую группу мы собрали загадки со сравнениями, где эталоном являются предметы быта, например:

*Кәкре-бөкре сызылган, Хәрефләре сыгылган, Асты бар, өсте бар, Тырма кебек теше бар (Язу); Элек үзе судан туды, Хәзер үзе су тудыра; Ак мамык кебек, Ялтырый алмаз кебек (Кар); Ялт-йолт ялтырый, Җирнең өсте калтырый, Энҗе кебек тезелә, Ефәк кебек сузыла (Яшен, яңгыр); Йомры-йомры туп кебек, Бөтен тәне шырт кебек (Керпе); Гармун кебек сырлы ул, Мич шикелле җылы ул (Җылыткыч батарея); Кешеләрне очырта, Үзе кошка охшамый; Зонтик кебек җәелсә дә, Җил-яңгырдан сакламый (Парашют); Үзе шардай, эче кандай, тәме балдай (Карбыз); Шар чаклы күзе бар, Йодрык чаклы үзе бар (Чынаяк)* [2]*; Мала, как мышь, Красна, как кровь, Вкусна, как мед (Вишня); За кудрявый хохолок Лису из*

*норки поволок. На ощупь – очень гладкая, На вкус – как сахар сладкая. (Морковь); Наши поросятки выросли на грядке, К солнышку бочком, хвостики крючком. Эти поросятки играют с нами в прятки. (Огурцы); Он большой, как мяч футбольный, Если спелый – все довольны. Так приятен он на вкус! Что это за шар? (Арбуз); Прозрачен, как стекло, А не вставишь в окно (Лед); Все обходят это место: Здесь земля Как будто тесто; Здесь осока, кочки, мхи Нет опоры для ноги (Болото)* [1].

Загадки, составленные с помощью таких сравнений, являются самыми многочисленными в обоих языках, так как данные предметы окружают человека в повседневной жизни.

Следующая группа сравнений в загадках – сравнения антропоцентрической направленности. Данные сравнительные конструкции встречаются в загадках обоих языков. Например: *Чылт-чылт күзле, Адәм төсле йөзле, Үчекләшер үзе, Ходайның боерыгы, Бардыр койрыгы (Маймыл); Балалары терерәк, аналары хуш күңеллерәк (Чәйнек һәм чынаяклар)* [2]*; Всегда шагаем мы вдвоем, Похожие, как братья. Мы за обедом - под столом, А ночью – под кроватью (Сапоги); Мала, как мышь, Красна, как кровь, Вкусна, как мед (Вишня)* [1].

Подводя итог, можем сказать, что в загадках также отражаются основные стереотипы народного сознания. Следовательно, сопоставительное исследование фольклорных произведений, их стилистических, функциональных и лингвокультурологических особенностей является основой для изучения национальной специфики языкового сознания.

**Литература**

1. Русские народные загадки. URL:https://zagadkisotvetami.ru/russkie-narodnyie-zagadki-s-otvetami (дата обращения: 15.01.2020).

2. Татарча табышмаклар. URL:http://maratkabirov.com/tostlar/tatarcha_tabyshmaklar.html (дата обращения: 15.01.2020).

3. Титова Н.Г. Доминантная функция загадки в русском и английском «сказочном» дискурсе // Вопросы современной науки и практики. – Казань, 2012. – С. 319-324.

## АССОЦИАТИВНОЕ ПОЛЕ ЛЕКСЕМЫ «СЧАСТЬЕ» В РУССКОМ ЯЗЫКОВОМ СОЗНАНИИ

*Ван Янь, КФУ, магистрант II курса*

*Науч. рук. – канд. филол. наук, доц. Э.А. Исламова*

Понятие языкового сознания появилось в 90-е годы прошлого века. Изучение языкового сознания даёт новую перспективу для изучения овладения языком и преподавания иностранных языков. В русской психолингвистике языковое сознание представляет собой комплекс образов сознания, сформированных и раскрытых с помощью языка. К языковым средствам относятся слова, словосочетания, фразеологизмы, тексты.

Лингвокультурология – комплексная область научного знания о взаимосвязи и взаимовлиянии языка и культуры, возникшая на основе исследовательских работ фразеологической школы В.Н. Телия, публикаций

В.В. Воробьева, В.Г. Костомарова, В.А. Масловой, трудов других лингвистов [2: 27]. Язык является внешним проявлением мыслительной деятельности человека и концептуальным выражением человеческого сознания, поэтому мы можем изучить сходства и различия языкового сознания различных народов с точки зрения лингвокультурологии, чтобы выявить специфичность языкового сознания.

Задача нашего исследования – изучить ассоциативное поле лексемы «счастье» в русском языковом сознании методом свободного ассоциативного эксперимента.

Эксперимент проводился в Казанском федеральном университете в декабре 2019 г. В анкетировании участвовали 106 студентов и магистрантов Института филологии и межкультурной коммуникация КФУ – носителей русского языка в возрасте 18-26 лет. Эксперимент был проведен в письменной форме. Участники в ответ на слова-стимулы должны были реагировать первым словом или словосочетанием.

Как показали результаты ассоциативного эксперимента, слово-стимул «счастье» вызвало у опрашиваемых широкий диапазон ассоциаций. Из 106 реакций на данный стимул число разных реакций 70, единичных реакций – 60.

В «Большом толковом словаре русского языка» дано следующее толкование лексемы «счастье»: «1. Состояние высшей удовлетворённости жизнью, чувство глубокого довольства и радости, испытываемое кем-л.; внешнее проявление этого чувства» [1: 1274]. Результаты нашего эксперимента подтверждают, что эти ассоциаты составляют ядро ассоциативного ряда слова «счастье» в русском языке.

Мы обнаружили, что слова-ассоциаты *радость* (10 реакций) и *семья* (10 реакций) являются самыми распространенными реакциями. В русском сознании самая большая особенность счастья в том, что оно заставляет людей чувствовать себя радостными и ощущать свою принадлежность к семье. *Любовь* (8 реакций) является одним из необходимых условий счастья. Трудно представить себе человека, который был бы счастлив, но одновременно никого не любил. Это подтверждают и другие реакции, связанные с проявлениями любви: *любимый человек 2, быть любимой 1, в любви 1, любить 1, любовь 1 и т.п.* Человеку для счастья необходимы близкие люди рядом, окружение, которое понимает и любит тебя и которому ты нужен: *мама и папа 2, быть нужным 1, в детях 1, вместе 1, друзья и семья рядом 1, жизнь и близкие люди рядом 1, знать, что ты нужен 1, радовать других 1, родные 1, ребёнок 1* и др.

Среди других составляющих счастья – *здоровье 4, спокойствие 4* и др. Очень важным условием счастья является состояние гармонии, удовлетворения: *в гармонии 1, гармония 1, состояние удовлетворения жизнью 1, умиротворённость 1.*

Некоторые опрошенные отмечают необходимость материального достатка, успеха – *благополучие 1, комфорт 1, успех в жизни 1, деньги 1.*

На периферии ассоциативного поля находятся слова с частотой 1, которые также дают представление о понимании счастья участников эксперимента: *вдохновение 1, глупость 1, грусть 1, долгожданное 1, жизнь 1, мечта 1, мирное 1, песни 1, природа и свобода 1, смех 1, солнечный день 1, хорошая музыка 1.*

В то же время участники эксперимента отмечают мимолетность, сиюминутность, даже недостижимость счастья: *мгновение 1, моменты 1, это то, чего нам сейчас не хватает 1.*

Среди ассоциаций отмечена единичная – *«счастье любит тишину»*, которая напомнила нам стихотворение Юрия Калугина.

Таким образом, ассоциативный эксперимент дает возможность исследовать структуру лексикона человека, его языковые и мировоззренческие приоритеты, ценностные ориентации.

**Литература**

1. Большой толковый словарь русского языка / Сост. и гл. ред. С.А. Кузнецов. – СПб., 1998. – 1536 с.

2. Коурова О.И. Традиционно-поэтическая лексика и фразеология как лингвокультурная ценность: монография. – Екатеринбург: Урал. гос. пед. ун-т, 2005. – 235 с.

## ЯКТАШ ШАГЫЙРЕБЕЗ ИҖАТЫНДА ПОЭТИК БИЗӘКЛӘР

*Вәлиева А., Буа р-ны Түбән Наратбаш мәктәбе, X сыйныф*

*Җит. – Л.Г. Шәрәфетдинова*

Тарихи елда Гөлнур ханым Айзетуллова шигырьләренең стиль үзенчәлекләрен ачыклау – яшь буынны, ягъни безне, патриотик рухта тәрбияләү өчен кирәк дип җавап бирер идем мин. Чыгышымның максаты – туган төбәгем шагыйрәсе Гөлнур Хәлил кызы Айзетуллова шигырьләренең образлы, поэтик бизәкләре турында мәгълүмат бирү.

Әйтелгән максаттан чыгып, түбәндәге бурычлар куелды: татар халкының мәдәни-тарихи мирасын, туган як әдипләрен өйрәнүгә кызыксыну уяту; Гөлнур Хәлил кызы Айзетуллова шигырьләренең образлы, поэтик бизәкләрен ачыклау; Тупланган материалны киң катлау укучыларына тәкъдим итү.

Җирле материаллар әсәрләрнең төп асылын тоярга ярдәм итә. Язучы иҗатын ул яшәгән мохиттән, ул туган, үскән, яшәгән һәм булган җирдән аерып карарга ярамый, чөнки бу мохит, аның язылачак әсәрләренә беренче тормыш тәҗрибәсе һәм материалы биреп, аның тирә-юньгә мөнәсәбәтенә йогынты ясый. Гөлнур Айзетуллова шигырьләрен укыганда, үз алдына туган ягын чын күңелдән яраткан, канатларын ныгыткан җиренә мәхәббәтен аңлаткан кеше образы килеп баса.

Буа үзенең туфрагында Әхмәт Рәшитов, Шәриф Хөсәенов, Ренат Харис, Барлас Камалов, Равил Рахмани, Гомәр Толымбай, Гомәр Гали һ.б.

бик күп язучы һәм шагыйрьләрне үстергән. Шигърияткә үз тавышы белән килеп кергән шагыйрәләрнең берсе – Гөлнур ханым Айзетуллова. Аның шигырьләренең тәэсир итү көчен фикер тыгызлыгы, фәлсәфи тирәнлек һәм образлылык арттыра. Шагыйрә лирик герое аша дөньяга, кешеләргә үз мөнәсәбәтен, үз карашын белдерә; иҗатында авыл, аның кешеләре, балачак, табигать, туган як, туган тел темалары урын ала.

Кешенең йөрәге аның кул йодрыгы чаклы гына, диләр. Әмма шушы бер йомарлам май шикелле генә йомшак, кечкенә йөрәккә үз гомерендә югалтулар, кайгы-хәсрәт кичерергә туры килә. Туры сүзле, кыю йөрәкле, ярдәмчел булып кала алды ул, сафлык, яктылык бүләк итүче шигырьләре тупланган «Бәхет гөле», «Өч мизгел» кебек китаплары бар. Аның яшәү мәгънәсе – башкалар өчен, милләте өчен янып яшәү.

Әсәрләрен укыганда, аның сүз байлыгына, тәмле, йомшак теленә сокланып бетеп булмый. Аның бер генә җөмләсендә дә берничә төрле энҗе бөртеге табып була. Миңем күңелемдә иң истә калган бер шигырендәге (“Китмә, Сөю”) бер генә җөмләне мисал итеп китерәсем килә:

Китмә, Сөю!
Күңелем гөлләренең
Чәчәк аткан чагы, китмә син!
Китмә, Сөю!
Сагыш утларыннан
Саргаеплар алар кипмәсен!

Бу юлларда эпитет та, сынландыру да, рефрен – җөмләнең кабатланып килүе дә бар. Минемчә, кабатлау юлы белән, автор укучыны уйландыруга да этәрә, бер үк вакытта хиснең көчен дә арттыруга ирешә.

Телнең мөмкинлеге чиксез. Безнең телебез – бай, бизәкле, гүзәл, үзенчәлекле, эмоциональ. Тел – аралашу чарасы. Ул һәрдаим җәмгыять тормышына катнашып бара, интеллектуаль, фикер процессының, сәяси, икътисадый, мәдәни эшчәнлекнең, бәйләнеш мөнәсәбәтләренең үзәгендә тора, боларга материал – мәгънәви кыяфәт бирә. “Тел – ул халыкның бар яшәеш дәверендә гасырлар, меңәр ел буена туплана килгән иң газиз, иң кадерл байлыгы, чынбарлыкны интеллектуаль үзләштерү, танып-белү, иҗат итү, фәлсәфи тирәлелек, фикерләү чагылышы”, – дигән иде тел галиме Хатип Миннегулов. Галимебез сүзен дөреслләп, шагыйрә иҗатына мөрәҗәгать итик.

Эпитет (грекча “ачыклагыч”, “өстәмә” дигән мәгънәдәге грек сүзеннән) – ачыклагыч сүз. Шагыйрә әсәрләрендә эпитетларның төрле сүз төркемнәреннән ясалганнарын куллана. Аның иҗатында исем, сыйфат, рәвеш эпитетларын очратырга була. Мәсәлән:

Җыр күгендә якты пар йолдыздай
Язсын иде озак яшәргә! (“Җырчылар Зәйнәп Фәрхетдинова һәм Зөфәр Билаловларга”)

Яңгырады затлы, моңлы көйләр:
Борынгысы, иң-иң кайнары.
Казанымнан алып килде аны
Үз халкымның моңлы Айдары (“Җырчы Айдар Фәйзрахмановка”)

Фәнни эшебезне йомгаклап, якташ шагыйрәбез Гөлнур Айзетуллова иҗатында сынландыруларның ролен ачыклау максатыннан, түбәндәге нәтиҗәләрне ясый алабыз:

1) автор поэтик бизәкләрне кеше хисләрен чагылдырганда бик урынлы куллана;

2) үзенең төп хезмәтенә багышлаган шигырьләрендә төрле поэтик бизәкләргә мөрәҗәгать итә;

3) сынландыруларда предметлар тойгы-хисне белдерергә сәләтле итеп һәм җанлы тереклек иясе кебек биреләләр. Аңа автор ихтыяры белән уйлау, фикер йөртү, күңелдән сөйләү сәләте тагылганлыгы аңлашылып тора.

Шагыйрә төрле чараларга мөрәҗәгать итә, дидек. Бу юлы без Гөлнур ханым иҗатындагы тропларның берсен – сынландыруларны (җанландыру) да тикшердек. Шагыйрәбезнең туган авылы Әнәле турында язганнарын укысаң, шунда ук үзең үскән авыл, аның инешләре, кыр сукмаклары, яшел чирәмнәре күз алдына килә. Шулар аша Туган җитебезнең матурлыгын, гүзәллеген тагын да ныграк тоярга ярдәм итте ул безгә.

## Г. ӘПСӘЛӘМОВНЫҢ «АК ЧӘЧӘКЛӘР» РОМАНЫНДА ҺӘМ АНЫҢ РУС ТЕЛЕНӘ ТӘРҖЕМӘСЕНДӘ СИНОНИМИК ПАРЛЫ СҮЗЛӘР

*Вилданова Ә., КФУ, III курс студенты*
*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Э.Н. Денмөхәммәтова*

Тәрҗемә итү ихтыяҗы кешеләр башка халыклар белән аралаша башлагач, сәүдә элемтәләре урнаштырырга кирәк булгач туа. Башта кешеләр көнкүреш сүзләрен генә тәрҗемә итсәләр, тора бара инде әдәби, мәдәни мирас белән дә алмашу теләге барлыкка килә. Тәрҗемә белеме зур тизлек белән алга барса да, бүгенге көндә тәрҗемә әсәрләрендә төгәлсезлекләр шактый. Аерым бер сүзне тәрҗемә итү зур кыенлык тудырмаса да, телебездә уникаль булган парлы сүзләрне тәрҗемә итүдә кыенлыклар шактый. Ни өчен дигәндә, парлы сүзләр ике сүздән тора һәм, күпчелек, фонетик яктан охшаш сүзләр була. Шуңа күрә андый сүзләрне тәрҗемә итү бик зур кыенлык тудыра.

Бүгенге көндә, югары технологияләр алга киткән, виртуаль аралашуга корылган заманда, парлы сүзләрне кулланып сөйләшүчеләр саны кими бара. Чөнки һәр кеше вакытны да, урынны да экономияләү максатыннан сүзләрне кыскартып язарга омтыла. Шулай да без социаль челтәрләрдә сораштыру уздырып карарга булдык. Сораштыруда 31 кеше катнашты. Сораштыруда катнашкан кешеләргә ике сорау бирелде: көндәлек сөйләмдә парлы сүзләрне кулланасызмы һәм ниндиләрен

кулланасыз? Сораштыру нәтиҗәләре буенча, 89% кеше көндәлек сөйләмдә парлы сүзләрне куллана, ә 19% катнашучылар кулланмый. Кулланучылар парлы сүзләрнең әти-әни, бала-чага, савыт-саба, көне-төне, аклы-каралы, алай-болай, ипи-тоз, фәлән-төгән, андый-мондый, килде-китте, юк-бар, сирәк-мирәк кебекләрен ешрак куллана.

Г. Әпсәләмовның "Ак чәчәкләр" романы – иң күп укыла торган әсәрләрнең берсе. Әсәрдә парлы сүзләр шактый күп кулланылса да, тәрҗемәдә алар юк дәрәҗәсендә. Чагыштырып карау өчен, без әсәрнең беренче бүлекчәсен анализладык һәм анда булган парлы сүзләрне һәм синонимик составлы парлы сүзләрне исәпләдек. Кечкенә генә әлеге өзектә барлыгы 37 парлы сүз (шуның җидесе составында синонимнар булган парлы сүзләр) очрый. Ә әсәрнең тәрҗемәсендә исә 7 (шуның берсе синонимик составлы парлы сүз) парлы сүз кулланылганлыгын күрергә мөмкин.

Әлеге парлы сүзләр ничек тәрҗемә ителгән соң? Әлбәттә, синонимик составлы парлы сүзне рус теленә дә парлы сүз белән тәрҗемә итү очраклары күзәтелмәде. Күп очракта алар ике синоним сүз өчен дә уртак мәгънә белдергән бер сүз белән генә тәрҗемә ителсә, кайбер очракта парлы сүз составындагы синоним берәмлекләрнең мәгънәсен үзгәртмичә, тиңдәш кисәкләр итеп тәрҗемә ителгән. Бөтенләй тәрҗемә ителмәгән синонимик парлы сүзләр дә бар.

Мәсәлән, "*Әнә бер хатын көянтә белән **иелә-сыгыла** су алып кайта, әнә ишегалды аркылы сузылган бауга кызыл башлы сөлгеләр кибәргә элгән"* [2: 15] – *"Вот женщина переходит улицу, **сгибаясь** под тяжестью коромысла*"[1: 16]. *Иелә-сыгыла* парлы сүзенең составын синонимик мәгънәле сүзләр тәшкил итә. Әлеге берәмлек "синонимнардан ясалган парлы сүзләр" исемлегендә бар [4: 253]. Парлы сүзнең компонентларын аерым алып карасак, синонимнар сүзлегендә *иелү (нагибаться, наклоняться, согнуться) – бөгелү,сыгылу,иңкәю, янтаю* кебек бирелгән. Димәк, парлы сүзнең компонентлары, дөрестән дә, синонимнар. Ә тәрҗемәдә бирелешенә карасак, ул *сгибаясь* фигыле белән генә алыштырып бирелгән. Шунысын әйтергә кирәк, рус телендә сүзләрне кушып парлы сүзләр ясалу төрки телләрдәге кебек продуктив ысул булып саналмый. Составында синоним берәмлекләр булган парлы сүзләрдә төп мәгънәгә ия сүз дип икенче сүз дип карала [3: 191]. Әлеге парлы сүздә дә тәрҗемәче икенче сүзгә басымны күбрәк ясап, сгибаясь дип тәрҗемә иткән, чөнки иелү сүзенең мәгънәсе рус телендә күбрәк *нагибаться, наклоняться* мәгънәләренә туры килә. Шулай да аларның мәгънәләре бик якын. Әлбәттә, рус телендә парлы берәмлек ясап, нагибаясь-сгибаясь дип тәрҗемә итеп булыр иде, ләкин бу, безнеңчә, отышлы түгел. Чөнки әлеге сүзләр, асылда, бер үк мәгънәгә ия һәм бары тик алкушымча белән генә аерылалар.

*“Кайбер пароходлардан җыр-музыка ишетелә”*[2: 12] – *“На некоторых пароходах звучит музыка, пение”* [1: 13]. Әлеге җөмләдә автор *җыр* һәм *музыка* сүзләрен парлы берәмлек итеп тәкъдим итә. Ә тәрҗемәче, шушы ук сүзләрне тәрҗемә итеп, тиңдәш кисәкләр буларак *музыка, пение* дип бирә. Синонимнар сүзлегенә мөрәҗәгать итсәк, “*җыр (песня) – җыру”; “музыка(музыка) – көй, моң, аһәң”* кебек вариантлар күрергә мөмкин. Игътибар итсәк, җыр һәм музыка сүзләре синонимнар буларак тәкъдим ителмәгән, шулай да автор аларны синонимик берәмлекләр итеп, парлы сүз составында биргән.

Парлы сүзләр гомумән тәрҗемә ителмәгән очраклар да күзәтелэде. *Мансур бар, ләкин кайдадыр бер читтә басып тора, якын да килми, ерак та китми, һәрвакыт шулай: күзгә күренә – сөйләшергә **тавыш-өне** юк”* [2: 14] – *“Вроде бы и виден Мансур, но не подойдешь, не поговоришь”* [1: 16]. *“Алар исәпсез-хисапсыз ташпулатлар диңгезендә ак кыялар төсле калкып торалар”*[2: 5]. – *“Освещенные каменные громады вздымались, точно скалы”* [1: 7].

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә кирәк: татар телендә парлы сүзләр еш кулланыла һәм сүз байлыгының аерылгысыз бер өлеше булып тора. Г. Әпсәләмовның “Ак чәчәкләр” әсәрендә әлеге караш дәлилләнә. Чынлап та, автор бик күп парлы сүзләр куллана. Ә аларны тәрҗемәдә бирү берникадәр кыенлыклар тудыра, чөнки парлы сүзләр куллану рус теле өчен гадәти күренеш түгел. Шулай да синонимик парлы сүзләрне тәрҗемә итү үзенчәлекле. Тәрҗемә иткәндә җибәрелгән хаталарны булдырмау һәм тәрҗемә өлкәсендә синонимик парлы сүзләрне аерым алып өйрәнүгә киләчәктә зур урын бирелер дип ышанып калабыз.

**Әдәбият**

1. Абсалямов А.С. Белые цветы: Роман. / Пер. с татарского К. Горбунова. Художник И. Субаев. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1987. – 560 с.

2. Әпсәләмов Г. Ак чәчәкләр: Роман. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. – 575 б.

3. Ерина Т.Н., Фомин Э.В. Жили-были. К проблеме парных слов русского языка // Вестник ЧГУ. 2016. №4.

4. Ханбикова Ш.С., Сафиуллина Ф.С. Синонимнар сүзлеге. – Казан: Хәтер, 1999. – 256 б.

## СӨЙЛӘШСӘК ТӘ ТӨРЛЕ ТЕЛЛӘРДӘ...

*Волков Т., Казан, 181 нче мәктәп, X сыйныф*

*Җит. – Ә.Ф. Вәлиуллина*

Мин – Тимур Волков, Василий улы. Әйе, исем-фамилиям урысныкы, ә үзем рәхәтләнеп татарча сөйләшәм. Милләтем буенча кем дисәгез, анысын да әйтеп үтәм: әниемнең әнисе – татар, әтисе – удмурт, әтиемнең әнисе – удмурт, ә әтисе керәшен. Менә сезгә башваткыч-мин кем булам соң? Миндә татар, удмурт, керәшен каны ага. Алар миңа барысы да якын. Ләкин гаиләбез белән татарча сөйләшәбез, татар халкының милли йолаларын хөрмәт итеп, барысын да үтәп яшибез. Татар хакының милли бәйрәмнәрен дә, дини бәйрәмнәрен дә, керәшен халкының Раштуа, Пасха бәйрәмнәрен дә гаиләбездә матур итеп

үткәрәбез. Казанда туып үссәм дә, мин еш кына әби белән бабай янына кайтырга тырышам. Теш табибы булып эшләүче әтием, укытучы, хореограф булып эшләүче әнием миңа авыл кешеләренең эчкерсезлеген, гадилеген, уңганлыгын кечкенәдән үк күреп үсәргә өйрәткәнгәдер инде, күңелем белән анда тартылам. Авылыбыз турында сезгә дә сөйләп үтәсем килә. Балтач районының Дорга дигән авылы ул – искиткеч гүзәл табигатьле, төзек матур авыл. Җыям дисәң – җиләге, гөмбәсе, эчим дисәң – салкын сулы чишмәсе, су коеныргa ,балык тотарга инеше бар. Яратам мин авылны! Моның сере бик гади-кечкенәдән абыйларга ияреп, көтү көтәргә чыга идем: иркен болынннарга, басу-кырларга карап, хәйран калып сокланып ята идем, бабам белән бергә Җанбит урманнарына барып, Шүрәленең "урындыкларын" карап йөри идек, әтием белән бергә балык тотарга төшкәч, кондызларның елга буйлап , ничек итеп тал ботакларын ояларына ташыганнарын күзәтә идек.

Дорга авылы – күпмилләтле. Татар, мари, удмурт, керәшен. Барчабыз да бертигез, милләтләрнең арасын олы дуслык бәйләп тора. Бу халыклар, әбием Фирдания сөйләве буенча, элек-электән бик дус- тату яшәгәннәр, бәйрәмнәрдә кунакларга йөрешкәннәр. Хәзер дә авылыбызда яшьләр арасында бу традиция саклана – бәйрәмнәрдә дәртле мари, удмурт, татар, чабата биюләрен биибез. Менә монда минем әбием Фирдания белән бабам Николайның өлешләре бик зур дип саныйм мин. Чөнки алар Дорга мәдәният йортында 45 ел эшләп, "Татарстанның атказанган мәдәния хезмәткәрләре" дигән исемгә лаек булдылар. Авылда беренче инструменталь ансамбль оештыручылар, Дорга көненә багышланган бәйрәмне уйлап табучылар. Авыл турында бик күп мәгълүмат җыеп, туплап, музейга тапшыручылар да алар... Һәм бик күп санап бетермәслек эшләр.. Лаеклы ялга чыксалар да, әле һаман да халыкка рухи байлык таратудан, халыкны агартудан туктамыйлар. Бабам турында аерым әйтеп үтәсем килә. Алексеев Николай Александр улы – оста гармунчы ,баянист. Аның кебек борынгы, моңлы татар көйләрен өздереп уйнаучылар сирәк. Удмурт милләтеннән булса да, 60лап татарча җыр иҗат итте. Җырчы Илсаф бабамның җырын зур сәхнәләргә алып чыкты. Удмурт милләтеннән булган бабам, татар әдәбиятын, мәдәниятен бар нечкәлекләренә кадәр beләдер кебек миңа. Ул өч телдә дә камил сөйләшә, уйлый, иҗат итә. Татар милләтеннән булган әбием, мари, удмурт, мордва халыкларының фольклорын иң яхшы белүчедер... Бабам белән әбием гомер буе сәхнәдә, төрле милләтле авылдашларының бер дус гаилә булып яшәүләрендә аларның өлеше зурдыр дип уйлыйм. Без дә калышмыйбыз, концертларда, бәйрәмнәрдә бергәләп бабамның җырларын татарча, удмуртча рәхәтләнеп җырлыйбыз. Ә бу юлга ничек килгән соң ул? Әбиемә мең рәмәт – ул уяткан иҗатка мондый мәхәббәтне, барыбызга да сеңдергән! Энем Булат белән без моны бөтен күңелебез белән тоеп, күреп, үсәбез. Минем алар

алдында бурычым – безгә бирелгән шушы матур тәрбияне алга таба да югалтмыйча, тулыландырып дәвам итү. “Теләк кирәк, теләк булса, бар да була,” – дип әйтергә ярата минем әни. Мин моның белән килешәм, бу бик дөрес сүзләр, чөнки Татарстаныбызда һәр милләт кешесе үз теленең матурлыгын, байлыгын күрә белсә, киләчәк буынга бу бит бик зур хәзинә! Телебезнең, милли йолаларыбызның, гореф-гадәтләребезнең киләчәге безнең кулда! Халыклар дус-тату гомер кичерсеннәр иде, еллар имин, табыннар мул булсын иде дигән теләктә каласы килә.

## Г. ИБРАҺИМОВ ҺӘМ Ш. КАМАЛ ИҖАТЛАРЫНДА МАРИНИСТИК ПЕЙЗАЖ

*Габдрахманова Л., Яр Чаллы педагогия көллияте, II курс студенты*
*Фән. җит. – филол. фән. канд. Р.Ә. Минһаҗева*

Диңгез образы гомер-гомергә халыкны үзенең сихри матурлыгы белән дә, көтелмәгән ярсулыгы белән дә җәлеп итеп торган.

Әдәбиятта диңгез темасының тамырлары борынгы мифологиягә барып тоташа. Татар әдәбиятында ул үз башлангычын Су бабасы, Су (кызы) анасы, Су иясе кебек борынгы легенда-риваятьләрдән ала. Су иясен ризалату, бәхилләтү өчен берәр кешене (гадәттә яшь кызны) диңгезгә корбан бирү гадәте дә булган.

Халкыбызның диңгезгә мөнәсәбәте фольклорда түбәндәге татар халык мәкальләрендә дә яктыртылган: *Диңгез янында кое казымыйлар / Диңгезгә барсаң, бүрегеңне онытма / Диңгезгә керсәң, чишмәдән су алырга онытма / Диңгездә булмаган – куркыныч күрмәгән / Диңгезне макта, корыны тапта.*

Сәнгатьтә диңгез күренешен сурәтләүчеләрне – *маринистлар* дип атыйлар. Килеп чыгышы белән бу сүз латин теленнән алынган, «marina» сүзе – «диңгез» дигәнне аңлата. Диңгезчеләр хәятен үзәккә куеп тасвирлау, диңгез маҗаралары, диңгез атрибутикасы, диңгез кичү белән бәйле сәяхәтләр – болар барысы да маринистлар ялатып сурәтли торган күренешләрдән санала. Корабларда океан-диңгез киңлекләрен гизеп, аның сихри гүзәллелеген дә, кырыслыгын да үз күзләре белән күргәннәр, диңгезнең «тозлы җилен» шактый татыганнар гына чын *маринистлар* булып санала алалар.

Безнең күзәтүебезчә, татар әдәбиятында диңгез темасына багышланган әсәрләр шактый. Диңгез арты илләренә сәяхәткә багышланган иң беренче татар сәяхәтнамәсе XVII гасырда Мортаза бине Котлыгыш әс-Симетинең хаҗга баруы турында язылган хаты санала [3: 163].

Бернигә буйсынмас шаулы диңгез образы белән без XIX йөз хаҗнамәләрендә, юлъязмаларында да очрашабыз. XX йөз башында Г. Тукай, М. Гафури, С. Рәмиев, Дәрдемәнд, Ш. Бабич, Н. Думави һ. б. иҗатларында чагылыш табуын күрәбез.

XX йөз башы прозасында маринистика жанрында каләмен сынаган әдип – Г. Ибраһимов. Аның «Диңгездә» (1911) хикәясендә [1], исеменнән үк аңлашылганча, төп вакыйгалар – диңгездә бара. Г. Ибраһимов диңгезне романтикларча, ирекле тормыш символы итеп сурәтләгән. Диңгез дулкыннары, вакыты-вакыты белән җил көчәюе аркасында туган куркынычлар кеше күңелендәге хисләрне тагын да тәэсирлерәк итеп сурәтләүгә ярдәм итә. Хикәя сюжетына исә пароходта танышкан Нуретдин карт хикәятләрен дә кертеп җибәреп, төрки фольклордан килгән зур балыклар турындагы риваятьләрне, хаҗнамә кыйссаларын бәян итә. Диңгез балыгына корбан бирү мотивын әүлия, изгеләрдән саналган Юныс пәйгамбәр язмышы белән үреп бирүе дә очраклы түгел. Ул киләчәктәге имин тормыш өчен бүген корбаннар соралуының борынгыдан килгән тамырлары хакында искәртә.

Диңгезнең үзенә килгәндә, Г. Ибраһимов диңгез образының бар киңлеген һәм бөеклеген күрсәтә алган: *күгелҗем шома диңгез; бөек диңгез; куркынулы диңгез; көмеш төсле; нурлы айлар белән зиннәтләнгән олы көзге кебек диңгез; иге-чиге булмаган диңгез; тын, авыр, куе диңгез.* Авторның чын мариначыл пейзаж остасы булуын күрәбез.

XX йөз башында нәкъ менә романтиклар иҗатында капиталистик шәһәр кешенең дошманы, халыкның канын суыручы рәвешендә килеп басса, хикәядәге шаулы диңгез образы исә бунтарь рухлы төп каһарман «мин»нең бозык рухлы шәһәргә карата гыйсъянын тулырак рәвештә гәүдәләндерергә ярдәм итүче образ булып калкулаша.

Ш. Камалның «Акчарлаклар» (1914) повестенда [2] диңгез пейзажы акчарлаклар, давыл, көймә образлары белән тыгыз үрелеп тасвирланган. Автор җанлы (акчарлаклар, тараканнар, кырмыскалар, ябалак-карчыга) һәм җансыз (ай, диңгез, давыл, җил, яфраклар) табигатькә иркен мөрәҗәгать итә. Алар я кешенең эчке кичерешләренә капма-каршы куелалар, яки инсан күңеле белән якын мөнәсәбәттә биреләләр. Диңгезгә чыгучы балыкчылар тормышынан булган һөнәри лексика: *невод, аркан, көймә, чаннар, ушатлар* да мариначыл пейзажны тулыландырып килүче компонентларга керә.

Ш. Камал эмоциональ тәэсир, буяуларны куертып күрсәтү максатыннан *җил, яңгыр, яшен, күк күкрәү* кебек сурәтләрне оста кулланган. Автор тасвирлаган диңгез һәрвакыт хәрәкәттә, тавышлар чыгара, сынландырыла, кешенең эчке кичерешләре белән аваздаш итеп бирелә. Ш. Камал да диңгез образын төрле мизгелләрдәге, төрле төсләрдә сурәтли: *ул کояшлы да, томанлы да, караңгы да, давыллы да, салкын да, елмаюлы да, хәсрәтле дә.* Әмма Г. Ибраһимовның мариначыл пейзажына караганда җыйнаграк һәм кыскарак. Аның каләменнән төшкән диңгез хәрәкәт итә, ыңгыраша, тетри, уфылдый, котыра, геройларының эчке

дөньясындагы хисләр бәрелешен чагылдыра. Диңгезнең халәте җилдән тора, дулкыннар да ул чакта гөҗләп килә. Бу тавышлар Гарифның эчен чымырдата, чәчләрен тырпайта. Шушы янәшәлек әсәрнең буеннан-буена дәвам итә: *«Ул барактан чыккач, үткен җил улавы арасыннан диңгез гөрләүләре белән бергә неводчыларның һай-һу тавышлары ишетелеп, аның күңелен әллә нишләтеп, борчып җибәрделәр»* [2: 217]. Әсәр ахырында укучы янә диңгез тасвирына юлыга. Аның өстендә сирәк-мирәк кенә акчарлаклар. Әллә көләләр, әллә елыйлар. Повесть менә шулай эчпошыргыч диңгез һәм хыял-өметләре җимерелгән балыкчыларның күңел халәтен сурәтләү белән тәмамлана.

Күрәбез, зур классикларыбызның бу әсәрләре хаклы рәвештә маринистик әдәбиятның иң матур үрнәкләрен тәшкил итәләр. Диңгез пейзажы ярдәмендә алар яшәү мәгънәсен эзләүче геройларының рухи дөньяларын ачканнар, күңел халәтләрен лирик-психологик төсмерләрдә сурәтләүгә ирешкәннәр.

**Әдәбият**


1. Ибраһимов Г. Әсәрләр: 9 томда. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1974-2000 (СССР фәннәр академиясе Казан филиалының Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм тарих ин-ты). Т. 1. Хикәяләр. (1907-1924). 1974. – 511 б.
2. Камал Ш. Сайланма әсәрләр. – Казан: Татар. кит. нәшр. – 2004. – 446 б.
3. Хәбибуллина Ч. Миргазиян Юныс – маринист әдип // Казан дәүләт университеты татар филологиясе һәм тарихы факультеты укытучыларының фәнни язмалары (2002). – Казан: РПФ «Гарт» нәшр., 2002. – Б.163-167.


## РОЛЬ ПОВТОРА В СОЗДАНИИ РИТМА И РИФМЫ В ПРОИЗВЕДЕНИЯХ ДЕТСКОГО ФОЛЬКЛОРА


*Габдуллазянова Г., КФУ, аспирант III курса*

*Науч. рук. – канд. филол. наук, доц. Р.С. Нурмухаметова*


Цель данной статьи – выявить основные виды повторов в текстах татарского детского фольклора. Прежде, обратимся к самому понятию «повтор».

«Повтор (удвоение, редупликация, повторение). Полное или частичное повторение корня, основы или целого слова без изменения их звукового состава (или с его частичным изменением) как способ образования слов, синтетических и описательных форм и фразеологических единиц…» [1: 327].

Повтор – это один из наиболее широко распространенных приемов в фольклорной традиции. Он встречается в различных жанрах, разнообразных произведениях и самых разных текстах, выполняя при этом разные функции.

Принцип повтора, проявляющийся на всех уровнях текстовой организации, выступает как один из важнейших принципов, обеспечивающих структурно- смысловое единство, целостность текстового пространства.

Появление повтора в фольклорном тексте объясняется устным бытованием фольклорного произведения. Повторяемость в произведениях устно-

го народного творчества придает им живописность, плавность, напевность; способствует замедлению развития действия в фольклорном произведении. Таким образом, «повторяемость – это одна из ведущих текстовых категорий, участвующих в структурно-смысловой организации фольклорного текста» [1: 327], в создании экспрессивности, в привлечении внимания читателя (слушателя) к важным в смысловом отношении описаниям.

Вопросно-ответные диалогические единства организованы по типу «ступенчатого» ввода новой информации. Такую особенность мы наблюдаем в татарских побасенках. Например, побасенка «Әби битен юмаган»:

*Әптчи, чумадан,*
*Әби битен юмаган.*
*Әби битен юар иде,*
*Комганда су булмаган;*
*Комганда су булыр иде,*
*Кызы суга бармаган;*
*Кызы суга барыр иде,*
*Көянтәсе булмаган...* [3: 134]

В тексте «Песи, кая барасың?» при помощи повторов образуется эллипс. «Эллипсис (брахилогия) – фигура речи, состоящая в пропуске какого-либо члена предложения, который подразумевается из контекста» [2: 218].

- *Песи, кая барасың?*
- *Әбиләргә барамын.*
- *Анда сиңа ни тия?*
- *Ике калак май тия.*
- *Аны кая куярсың?*
- *Мич астына куярмын…* [4: 69]

Каждое повторяющееся слово в конце каждой строчки создает парную рифму: *барасың – барамын, тия – тия, куярсың – куярмын* и т.д.

В татарских колыбельных песнях встречаются различные повторы: аллитерации, ассонансы, синонимы, тавтологические слова и выражения, повторы слов в одном стихе, повторы начальных слов смежных стихов, цепевидных повторений слов смежных стихов, повторений целых стихов, местоимений с предлогами и без предлогов, служебных слов, звукоподражаний. Одни участвуют в создании системы обращений, другие придают повествованию динамику и в то же время обеспечивают однотонный ритм. Например:

*Әлли-бәлли*: йом син күзең,
*Әлли-бәлли* – татлы сүзем.
*Йоклый инде* бөтен бәбиләр дә,
*Йоклый инде* хәтта әбиләр дә [3: 78].

Широко используются в народных загадках повторы слов, разных форм одного слова, однокоренных слов, частичная омонимия корней, аллитерации

вместе с синтаксическим параллелизмом частей – так народная мудрость отражает сложность и противоречивость явлений и устройства мира в целом:

*Зур мичкә өстендә кечкенә мичкә,*
*Кечкенә мичкә өстендә кара урман (Кеше гәүдәсе)* [4: 76].
*Ике агай суга бара,*
*Берсен берсе уза бара (Аяклар)* [4: 88].
*Өй эчендә биш бала,*
*Билгесендә биш тана (Кул, бармаклар, тырнаклар)* [4: 82].

Таким образом, проанализировав тексты из разных фольклорных жанров татарского детского фольклора, мы можем заключить, что наиболее употребительны анафорический и эпифорический типы повторов отдельных слов, словосочетаний, предложений.

Одной из главных функций, которые выполняют различные виды повторов в произведениях устного народного творчества, является создание его экспрессивности, мелодичности, напевности. Повторы в исследуемых фольклорных текстах обеспечивают связность текста.

**Литература**

1. Ахманова О.С. Словарь лингвистических терминов. – М.: Едиториал УРСС, 2004. – 576 с.
2. Приходько В.К. Выразительные средства языка. – М.: Академия, 2008. – 218 с.
3. Урманче Ф.И. Татар халык иҗаты. – Казань: Магариф, 2005. – 288 с.
4. Ягфаров Р.Ф. Татар халык иҗаты: балалар фольклоры. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1993. – 267 б.

## Г. САБИТОВ ХИКӘЯСЕНДӘ ОБРАЗ ТУДЫРУ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

*Габдуллин Р., КФУ, II курс студенты*
*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Г.Р. Гайнуллина*

Г. Сабитовның “Урман кызы Таңсылу” (1981) хикәясенә алынган мотивны автор җанр атамасы белән үк тамгалый. Әсәр тукымасына тылсымлы хикәя дип билгеләнгән өлештән үк кереп кителә. Сюжет сызыгы урман кызын табуга бәйле Булат – Кәли мөнәсәбәтләренә корыла. Кичерешләр сызыгын зирәк карт архетипик моделе һәм аның кабатланышы каймалап ала: “Сәер кеше бу Газизулла абзый. Гомере буе урманда яшәп тә һаман күңеле урманнан бизмәгән” [1: 25]. Ата кешенең бурычы – улының күңел тәрәзәләрен ачу дип инанган Газизулла. Автор-хикәяләүче укучысына курай моңын, Карурман бабай җырын ишеттереп алдан ук психологик эчтәлек дулкынына көйли. Урман кызы Таңсылуның барлыгын белү Булатны сер дөньясына алып керә, ул хәзер аны табу өчен таң вакытында уяу булыр. Шул рәвешле, уяу һәм игътибарлы булу гамьсезлеккә каршы куела.

Булатның кичерешләр чылбырында таң вакыты образына салынган эчтәлек символик укылышлы. Малайның психологик халәтендә гаҗәпләнү, соклану тойгысы балада әлегә ачылып кына килүче күңел күзе турында

белдерү урыны: “Гаҗәп.Таң вакытында урман тылсымлы бер төскә керә икән! Агач асларында куе күләгә, тау куышы кебек караңгы. Ә кояш төшкән урыннарда агачлар ачык яшел төстә. Һәр агачта, һәр ботакта меңләгән чык бөртекләре. Аларның һәрберсе, күзләрнең явын алырлык булып, төрле төсләр белән балкый. Үләннәрдәге чыклар да бик кызык: кояш төшкән урында алан өсте күзгә кырау төшкән төсле ап-ак, ә күләгә җирдә – куе зәңгәр. Әйтерсең кемдер төн буе зәңгәр буяу сибеп йөргән!” [1: 27].

Булат өчен үзен җәлеп иткән гүзәл күренешләрне башкаларга күрсәтү мөһим. Фотосурәтләрнең “Күңел күзе” газетасына урнаштырылуы – матурлыкны тояр өчен күңел күзе белән карау кирәк дигәнне аңлата. Монда үзеңнең генә түгел, башкаларның да күңел күзен ачарга мөмкинлек тудыру белән дә кеше бик бәхетле була ала дигән фикер тоемлана.

Пейзаж элементы ярдәмендә автор самими бала күңелендә туган һәр яңа хиснең никадәр тулы, бөтенлекле кичерелеше хакында әйтә. Малайның әлеге ачышы алдагы вакыйганы – аланга кергәч урман кызы белән очрашуны әзерли. Таңсылу Булатны кәүсә эчендә каен суы акканын тыңларга, таң энҗесеннән энҗе сәйлән тезәргә өйрәтә. Булат берсүзсез Карурман бабай кызына буйсына, тик ромашка чәчәгенең чык бөртегеннән сәйлән тезү генә җиңел эш түгел икән. Автор кеше күңеленең кылларын энҗе сәйлән белән чагыштырып, күңелне аңлау, рух тирбәнешләрен тыңлау зур хезмәт, тырышлык, сак якын килү сорый дип кисәтә кебек. Ләкин үз күңелең тәрәзәләрен ачу һәркемне матур юлга алып чыга, үз асылын, табигатен аңларга ярдәм итә.Таңсылу образында тупланган Матурлык образы – Булат күңелендә әлеге гүзәллекнең укылышы, табылуы ул: “Бөтенләй якында гына, әлеге каен агачы төбендә Таңсылу басып тора!.. Нинди чибәр кызый! Йөзе алмагач чәчкәсе төсле алсу, чәчләре коңгырт-кара. Дулкын-дулкын булып, бөдрәләнеп иңнәренә төшкән. Яшел чигүле ап-ак күлмәк кигән. Ә күзләре... күзләре нинди! Һавага караса, алар ачык зәңгәр, урманга караса – коңгырт, ә чыклы үләнгә караса, чыклы үлән кебек ялтырый башлыйлар”[1: 29].

Автор-хикәяләүче Булатның кичерешләр сызыгын таң калу ноктасына җиткерә: “Ул иелә-бөгелә үләннәрдән, чәчкә керфекләреннән чык бөртекләре җыеп ала да, аларны неп-нечкә пәрәвез җебенә тезеп, кат-кат итеп муенына тага.Таң энҗеләре шунда ук әллә нинди сихри нурлар белән җемелдәшә башлыйлар. Таңсылу өнсез калган Булатка карап елмая” [1: 29].

Күңел кылларының яңа дулкыннары Кәли белән Булатның фотосурәт төшерү һәм ясау вакыйгасында чагылыш таба. Булат төшергән рәсемнәр бөтен кешене таң калырга, болай гади генә тоелган табигать мизгелләренә яңа күзлектән карарга мәҗбүр итәләр. Фотосурәтләрнең “Күңел күзе” газетасына урнаштырылуы берсүзсез символик яңгырашлы. Күңел күзе ачылу – тормыш-чынбарлыктагы гади генә тоелган, инде күнегелгән күренешләргә яңа күзлектән

карый алу, һәр мизгелнең матурлыгын тоя башлау, һәр вакыйга-гамәлнең сәбәп-нәтиҗә бәйләнеше булын төшенү ул, ди автор: "Беренче рәсемдә шул кошчык. Ул бер куаклыкның иң түбәнге ботагына кунган да, канатларын җәеп, авызын зур ачып түбәнгә карап тора. Нәрсәгәдер борчылганы, нәрсәдәндер бик нык курыкканы әллә каян күренә. Ә җирдә кап-кара агулы елан. Гаҗәп! Анысын Булат бөтенләй күрмәгән иде.. Икенче рәсемдә тагын да кызыграк хәл!..Кошчык башка ботакка күчеп утырган. Бераз гына читтәрәк аның оясы. Ояда әле каурый чыкмаган дүрт кош баласы. Куак астыннан бер керпе чыгып килә. Елан, авызыннан ике япьле угын чыгарып, керпегә ташланырга тора... Өченче рәсемдә – кошчык тынычланып балалары янына барып утырган. Ә керпе бик тәмләп кенә елан ите ашап утыра" [1: 38-39].

Карурман бабай сүзләре архетипның кабатланышы булып хикәяне каймалап алган Газизулла теле белән әйттерелә, автор-хикәяләүченең укучыга әйтергә теләгән фикере буларак кабул ителә: "Юк, балалар, урманда сез куркырлык бернәрсә дә юк. Шатланыгыз гына, сезнең күңел күзләрегез ачылган. Күңел күзе чыклы алан өстеннән күтәрелгән ак томанны да гүзәл урман кызы итеп күрә, карт имәнне дә серле дирижерга, җырчы Карурманга охшата. Менә инде хәзер минем күңел тыныч. Сез Карурман җырын ишеткәнсез. Кабат беркайчан да ул сезнең күңелегездән чыкмас. Саф күңелле кеше булып үсәрсез"[1: 42]. Шул рәвешле, автор кичерешләр чылбырын табигать сурәтенә, портрет, пейзаж элементларына, мифологик образ, мотивларга салып тезә.

Йомгаклап шуны әйтәсе килә, Урман кызы Таңсылу хикәясендә Г. Сабитов табигатьнең матурлыгына сокланып күңел күзен ачырга омтыла. Г. Сабитов иҗаты – тирән фәлсәфәле иҗат.

**Әдәбият**

1. Сабитов Г. Кайнар туфрак: хикәяләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. – 160 б.

## ЛИНГВОСТРАНОВЕДЕНИЕ КАК ОБЛАСТЬ МЕТОДИКИ И ЛИНГВИСТИКИ

*Габдуллина А., КФУ, студент V курса*

*Науч. рук. – канд. филол. наук, доц. А.Х. Ашрапова*

Усвоение любого иностранного языка – это усвоение новых понятий, которые отражают культуру и выражаются различными языковыми средствами. Уникальность каждой культуры проявляется в сочетании универсального и национального восприятия мира, что отражается в языке и формирует своеобразную лингвистическую картину этого мира.

Разные национальные стереотипы формируются в разных лингвокультурных сообществах по отношению к одним и тем же культурным явлениям. Одни и те же реальности, концепции могут иметь разные интерпретации в разных культурах, т.е. разную семантику, и могут быть связаны с разными сферами духовной жизни. Несоответствие между лингвистическими картинами мира в определенных областях разных языков определя-

ется как национально-культурная специфика, незнание которой затрудняет понимание иностранной культуры и вызывает коммуникативные конфликты при общении на иностранном языке.

Для реализации успешного межкультурного общения в процессе изучения русского языка как иностранного становится необходимым предусмотреть, объяснить, предотвратить неадекватные ассоциации, обусловленные культурными, историческими, социально-психологическими особенностями и самобытностью национальной культуры студентов и культуры. изучаемого языка.

Круг проблем, связанных с включением русской культуры в процесс преподавания русского языка иностранцам, был обозначен в работах Е.М. Верещагина и В.Г. Костомарова, в результате чего в теории и практике преподавания русского языка как иностранного возникла дисциплина, называемая линвострановедение.

Лингвистические и культурологические исследования – это область лингвистики, которая занимается изучением национально-культурных особенностей в лингвистических единицах, исследует элементы семантики, отражающие национальную культуру.

Работая с иностранными студентами, учитель должен включать в содержание своей учебной информации и рекомендации о реалиях страны изучаемого языка и стереотипах поведения его носителей. Национальные стереотипы существуют в каждой культуре, и их существование имеет очень глубокий социальный, культурный, психологический и коммуникативный смысл. Незнание норм поведения может нарушить общение, привести к так называемому культурному шоку или коммуникативному конфликту.

В каждой культуре существуют традиционные способы приветствования, знакомства, поздравления, ссоры. В таких или подобных ситуациях русские, точнее говоря, все принадлежащие к русской культуре, ведут себя в соответствии с шаблоном, выработанным веками, то есть стандартом, который обеспечивается стереотипами поведения.

Наличие на языке слов, обозначающих элементы национальной культуры, быта, национальной одежды, кухни, слов, обозначающих имена, фамилии, топонимы и т.д. затрудняет общение из-за их уникальности и отсутствия эквивалента на родном языке учащегося.

Огромный вклад в рассмотрение социальной обусловленности содержания семантики слова, а также в развитие общетеоретических и методологических аспектов проблемы «языка и культура» внесли лингвисты Н.Г. Комлев, О.С. Ахманова, Е.М. Верещагин, В.Г. Костромаров, Т.Д. Томахин.

Изучение культурной составляющей слов является важным условием успешного овладения иностранным языком, однако, в свою очередь, оно входит в более широкий спектр культурно-исторических значений

соответствующей социальной реальности, усвоение которой является Важное условие использования языка как средства общения. Так, например, О.С. Ахманова отмечает, что непременным условием реализации любого коммуникативного акта должно стать «взаимное знание реалий говорящего и слушателя, являющееся основой языкового общения», получившее в лингвистике название «фоновые знания» [1].

В.С. Красильникова подробно описала различные виды работы с материалами лингвокультурологии: работа с текстом лингвокультурологии; работа с картинками; работа с географическими картами; работа со знаками и символами культуры; работа с отчетами по проекту и конкретной стране [3: 11].

Эта работа является результатом регионального географического и лингвистического содержания. Квиз, проведенный в разных странах это не только общий вопрос. Он состоит из нескольких предложенных вариантов (multiple choice). Его универсальность в том смысле, что он используется на разных этапах.

Таким образом, лингвокультурологический подход в целом способствует формированию стереотипов национального мышления и обеспечивает возможность успешного межкультурного общения. Особая роль в этом подходе к обучению отводится аутентичным текстам для чтения и прослушивания. При таком подходе возможны различные формы работы и контроля: работа с картинками, текстами, викторинами, видеоматериалами, географическими картами, знаками и символами культуры. В целом, лингвокультурный подход активно способствует достижению цели (овладению коммуникативной компетенцией студентов) относительно простым и интересным способом.

**Литература**

1. Ахманова О.С. Словарь лингвистических терминов. – М.: Рипол-Классик, 2013. – 608 с.
2. Верещагин Е.М., Костомаров В.Г. Лингвострановедческая теория слова. – М.: Русский язык, 1980. – 320 с.
3. Красильникова В.С. Лингвострановедческий подход в определении содержания обучения английскому языку // Иностранные языки в школе. – 1993. – № 1.

## И. ЮЗЕЕВНЫҢ «МӘҢГЕЛЕК БЕЛӘН ОЧРАШУ»ПОЭМАСЫНДА СИМВОЛИК ОБРАЗЛАР

*Габидуллина Э., КФУ, II курс магистранты*
*Фән. җит. – филол. фән. докт., доц. Н.М. Йосыпова*

И. Юзеевның «Мәңгелек белән очрашу» поэмасы – мотивларга таянып язылган әсәр. Трагедия тематик-проблематик яссылыкта ике юнәлешне колачлый: сугышларның вәхши нигезен фаш итү һәм вакыт белән кеше арасындагы якынлык һәм табигый каршылык турындагы уйлану.

Әсәр нигезенә салынган мифологик сюжет кайчандыр юкка чыккан Атлантида турында Платон язып калдырган мифка, легендага корылган.

Ул археолог Атлантның, югалган Атлантида утравын эзләгәндә яраланып, җир асты патшалыгына эләнүе, грек аллалары белән очрашуы һәм Зәңгәр күкләр алиһәсе Афина ярдәме белән Күккә очуы турында бәян итә, шул җирлектә Аллалар белән конфликт төенләнә [3: 70].

Шагыйрь Атлантида образын яңартып, тормышның идеаль яшәеш моделен тергезә. Әлеге ике дөньяны салават күпере тоташтыра һәм символик яссылыкка реаль һәм ирреаль дөньяларны тоташтыручы күчеш чиге булып формалаша.

Атлантның фантазиясе, уйдырмасы әсәр ахырында хәзерге вакыт, чын барлык кебек тәкъдим ителгән дөнья белән тоташа һәм каһарманның хыял юлындагы этапларын символлаштыра. Атлантның төп максаты хәзерге көн кешеләренә үткән заманнар тәҗрибәсен, ялгышларын исәпкә алырга һәм киләчәккә дөрес юлдан барырга кирәклекне өйрәтүдән гыйбарәт.

Фәлсәфә символ дәрәҗәсенә күтәрелгән мифологик сюжет аша ачыла, ул кеше яшәешенә мөнәсәбәтле фикерләрне бер җепкә тезә. Мифологик күзаллау җиһанны өч дөньядан тора дип саный: күк дөньясы, адәм балалары яши торган җир өсте һәм кешеләр бу дөньядан киткәч иңә торган җир асты дөньясы. Әлеге әсәр сурәтләгән дөньяда аларның өчесе дә тергезелә, фәлсәфәне җиткерү барышында шартлы төстә күк дөньясы һәм җир асты дөньясы кушыла. Әнә шулай миф сюжеты җир һәм күкне берләштерә, әсәр тукымасында алар ике катламлы тормыш моделен тергезә.

Шагыйрь фәлсәфәне җиткерү өчен әсәрнең төп геройларын Атлант һәм аның улы Икарны символ буларак файдалана. Әсәрдә Атлант горур, максатчан, көчле кеше буларак ачыла, реаль һәм идеаль дөньяларны тоташтыручы герой итеп бирелә. И. Юзеев Икарны көчле рухлы, киләчәк буын вәкиле дәрәҗәсендә сурәтләп ача [3: 70].

Әсәр аша уздырылган фәлсәфәне җиткерү барышында әлеге образлар белән янәшәдә мифик грек Аллалары да ярдәмгә килә. Шагыйрь аларны, әсәр башында ук аерып куеп, Аллалар дип билгели һәм символ буларак ачылганда да бу мәгънә саклана. Борынгы грек Аллалары - Олимп тавы хуҗалары – баш алла Зевс һәм аның балалары: Афина – Зевсның башыннан барлыкка килгән Зәңгәр күкләр алиһәсе, Аид – җир асты алласы, Арей – сугыш алласы, Ананка – язмыш алласы – барысы да билгеле бер мәгънә бөтенлеген яңарта. Алар һәркайсы әсәр структурасында чагылыш тапкан өч дөньяны – җир, күк һәм җир астын төгәлләштереп куя. Әсәрдә Аллалар – явызлык идеалының гәүдәләнеше, символы. Явызлыкның эчтәлеге булган кансызлык, гаделсезлек, мәкер, шәфкатьсезлек кебек сыйфатларның илаһи югарылыкта бирелүе поэмада хис көчәйтү өчен кирәк [1: 98].

Әсәрдәге Аллалар ике яклы сурәтләнә: яманлыкка йөз тотканнары белән янәшәдә игелеклелек идеалы буларак гәүдәләнгән Аллалар да бар.

И. Юзеев Афинаны яхшылык билгесе итеп сурәтли, Атлантида фаҗигасенең сере дә аның аша ачыла. Афина адәмнең Аллалар дөньясына изге нияттә килүенә төшенеп, хакыйкатьне яклый. Әсәр тукымасында ул тыныч-имин дөнья идеалын алга куя. Ул – илаһи матурлык белән бөек акылның иң камил дәрәҗәсен күрсәтүче романтик югарылыктагы гүзәллек символы.

И. Юзеев шушы шартлы персонажлар ярдәмендә кешенең эчке дөньясы гармониясен, югары һәм куәтле көчләр алдында азатлык проблемасын яклап чыга. Шагыйрь, Матурлык һәм Яхшылык күпме генә үзенә тартса да, дөньяда әле Яманлыкның да яшәвен искәртә. Трагедиядән шундый идея алга чыга: Яхшылык һәм Мәхәббәт, Вөҗдан белән бер сафта басып, намуссызлыкка, кабахәтлеккә, хыянәтчелеккә бердәм булып каршы чыгарга тиешләр.

Шул рәвешле, шагыйрь борынгы юнан мифологиясен, шәрык дин фәлсәфәсен, татар мифологиясен файдалана, гомум кабул ителгән мифологик структуралар ярдәмендә яхшылык һәм явызлык каршылыгын төрлечә укылышка ия катлаулы әсәр нигезенә сала. Җир йөзендә явызлык мәңгелек, яхшылык кеше гомере кебек чикләнгән, диюче автор фикеренчә, һәркем, акылының камиллегеннән чыгып, мәңгелекне үзенчә күрә, күзаллый, димәк, мәңгелек белән очрашуы аның үз хыялы, үз-үзе белән очрашу, үз-үзен танып-белүе, бәяләве булып тәгалләшә [3: 74].

**Әдәбият**


1. Даутов А. И. Илдар Юзеев шигъриятендә романтизм. – Казан: “ИНТЕЛПРЕСС”, 2002. – 152 б.
2. XX гасыр татар әдәбияты тарихы: 2 кисәктә. К.2. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 2011. – 252 б.
3. Татар әдәбияты тарихы: Алты томда: 60-90 еллар әдәбияты. – Казан, “Раннур” нәшр., 2001. – 544 б.
4. Юзеев И. Соңгы төн // Юзеев И. Мәңгелек белән очрашу: шигырьләр, поэма, трагедияләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. – 354 б.


## Ә. ЕНИКИ ПУБЛИЦИСТИКАСЫНДА БӨЕК ШӘХЕСЛӘР ЯЗМЫШЫ


*Гайнуллина Д., Казан, 155 нче гимназия, X сыйныф*

*Җит. – М.Х. Хәсәнҗанова*


Татар әдәбиятының йөзек кашы, күренекле язучы Әмирхан Еники (1909–2000) публицистик мәкаләләрендә үзе күргән, белгән шәхесләр турында күп яза. Әдип татарның йөзек кашы булган Г. Тукай, Г. Ибраһимов, Г. Исхакый, Һ. Такташ, С. Кудаш, Х. Туфан, С. Сәйдәш кебек шәхесләр турында бик күп мәкаләләрендә искә ала.

Ә. Еники – Г. Исхакый исемен җәмәгатьчелеккә кыю рәвештә беренчеләрдән булып кайтарган әдип. «...Без дә бардык Төркиягә...» дигән баш атында дөнья күргән мәкаләсендә (1996) Ә.Еники Г. Исхакый белән Й. Акчура каберләрен зират итәргә баруы хакында билгеләп үтә. Татар әдибенең Й. Акчура кабере янындагы хисләре болай бирелә: «Бик әйбәт сакланган кабернең ташы безне аеруча гаҗәпләндерде һәм сокландырды.

Ул таш – кечерәйтелгән Сөембикә манарасының нәкъ үзе иде!.. Мәрхүмнең васыяте беләнме, әллә кызларының акылы җитепме эшләнгән бу таш Сөембикә манарасы – олы шәхеснең туган иле белән мәңгелек бәйләнешен чагылдырган символы буларак басып торадыр» [1: 277]. Шунда Ә. Еники Кәрим Тинчуринның җәмәгате Заһидә Әхмәрова сөйләгән вакыйганы бәян итә: «1921-1922 ачлык елларын Кәрим абзый белән Заһидә апа Ташкентта уздыралар. Шул чагында аларга гаязның аылда калган үсмер кызын кемдер китерә (ихтимал, бу алдан хәбәрләшү буенча эшләнгәдер, дип уйлыйм мин). Сәгадәт авыр кышны Заһидә апаларда торып үткәрә. Егерме икенче елның җәендә Ташкенка Галимҗан Идриси (шулай ук бик билгеле шәхес килеп Германиядә кытыр өчен шәкертләр җыя. Ул үзе Берлин университетының укытучысы була. Җыйган шәкертләре белән Идриси Тинчуринардан Сәгадәтне дә алып китә. Менә шул кешеләрнең игелеге аркасында Гаяз Исхакый бердәнбер кызы белән Берлинда очраша» [1: 278].

«Таң ата да кич була» язмасында (1998) Ә. Еники болай яза: «Мин яшем белән бер-берсенә һич охшамаган ике буын арасына туры килдем: иске буын әле китеп бетмәгән, ә яңасы туып, күтәрелеп кенә килә иде... Искеләре дигәнем гасыр башында мәйданга чыгып, милли мәдәниятебездә күренекле урын тоткан шәхесләр – Фатих Әмирхан, Галимҗан Ибраһимов, Галиәгар Камал, Җамал Вәлиди, Гали Рәхим, Садри Җәләл һ.б.» [1: 76]. Шул урында әдип сүзне җырчы, нәшир, журналист Камил Мотыйгый шәхесенә күчерә: «Мин Камил абыйны күреп белә идем» [1: 424], – дип ачыклап киткәннән соң, әдип аның белән онытылмас очрашуларын, Камил Мотыйгыйның фаҗигале язмышын сөйләп бирә: «...Уральскийдан татар халкының бик тиз танылачак һәм яратып укылачак, чын мәгънәсендә хөр фикерле милли шагыйре күтәрелеп чыга... Һәм турыдан-туры Камил Мотыйгулла улы Төхфәтуллин аркасында» [2: 429].

Күренгәнчә, Ә. Еники халыкны таныткан шәхесләргә бәйле шактый кызыклы һәм кыйммәтле язмалар бирә. Ләкин язмалар шул шәхесләр алып килгән бөек рухны югалтуга әрнү, эчке бер сызлану белән өретелгән..“Шагыйрь ерак сәфәрдән кайтты” дип исемләнгән мәкаләсендә (1962) Сәгыйть Сүнчәләй мирасы турында болай яза: “..билгеле тарихи сәбәпләр аркасында Сәгыйть Сүнчәләй утыз елдан артык безнең әдәбиятыбыздан югалып торды” [2: 10]. Мәкалә утыз биш ел үткәннән соң С. Сүнчәләйнең беренче кечкенә шигырь җыентыгы дөнья күрү уңаеннан языла. Ә. Еники С. Сүнчәләйнең кулъязмаларының саклануы, 1959 елда Шәриф Сүнчәләйнең шагыйрьнең барлык шигырьләрен, сәхнә әсәрләрен, тәрҗемәләрен, истәлекләрен, рәсемнәрен җыеп, туплап, аңлатмалар биреп, библиографик белешмәләр язып, әзер җыентык итеп нәшриятка тапшыруын әйтә. Ә. Еникине борчыган мәсьәлә: “шул җыентыкның

бердәнбер законлы төзүчесе булган кешенең исеме хәзер басылып чыккан китапның бер җирендә дә күрсәтелмәгән булуы” [2: 10]. Язучы гомерен халыкка хезмәткә багышлаган шагыйрьнең Г. Тукай белән дустанә мөнәсәбәтләре темасын да калкыта. Ә. Еники С. Сүнчәләйнең Г. Тукайга багышлап биш истәлек, җиде шигырь язганлыгын билгеләп үтә. “Мәрхүм Ә. Фәйзи Тукайның Сүнчәләйгә язган хатлары һәм Сүнчәләйнең Тукайга багышланган истәлекләре, шигырьләре белән танышкач, боларның барысын да “Тукай һәм Сүнчәләй” дигән исем астында кечкенә бер китап чыгарырга кирәк дип әйткән иде” [2: 17].

Ә. Еники татар музыка сәнгатенең беренче профессиональ композиторы С. Сәйдәшев иҗатына аеруча игътибарлы, һәм публицистикасында, һәм әдәби иҗатында аның эчке дөньясына кайта-кайта мөрәҗәгать итә: “Сәйдәш шәһәр баласы, үз заманының алдынгы татар зыялылары арасында үсеп җитешә, шәһәр культурасы белән сугарыла. Салих Сәйдәш бөтен килеш-килбәте белән бик пөхтә, чибәр, нәфис бер кеше иде. Һәм музыкасы да аның якты, нәфис ... һәм күтәренке-дәртле дә иде” [2: 76]. Композиторның эчке зыялылыгы турында сөйләгәндә әдип бер вакыйгага туктала: “Бер заман газетада нинддер уңай белән бүләкләнгән сәнгать әһелләренең исемлеге басылып чыга. Вакыйганы сөйләүче – шагыйрь – шул газетаны сатып алып, урамда карый-карый бара. Аңа Сәйдәш очрый. Туктыйлар, исәнләшәләр. Шагыйрь газетаны күрсәтеп әйтә: менә монда ни өчендер синең исемең юк, ди. Шуңа каршы Салих тыныч кына: “Ник булмасын, минем Салих Сәйдәш дигән исемем бар”, – дип җавап бирә” [2: 80].

Шул рәвешле, Ә. Еники XX йөз башында иҗат итеп, үзләреннән соң гаҗәеп зур мирас шәхесләр, аларның татарны дөньяга танытуда роле, фаҗигасе турында сызланып яза.

**Әдәбият**

1. Еники Ә.Н. Әсәрләр. Биш томда. V том. Публицистик язмалар, мәкаләләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. – 479 б.

2. Еники Ә. Хәтердәге төеннәр: Мәкаләләр, очерклар һәм истәлекләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1983. – 224 б.

## РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕНЕҢ ТӨРКИ АНТРОПОЛИСОНИМНАРЫ

*Гайфуллина И., КФУ, II курс магистранты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Г.К. Һадиева*

Кеше, җәмгыять чолганышында яшәүче җан иясе буларак, исемсез яши алмый. Шунлыктан сәяхәтчеләр цивилизациядән читтә яшәгән, мәдәни, икътисади һ.б. яклардан иң артта калган кабиләләрдә дә кешенең исеме булуы турында язалар. Борынгы заманнарда ыруг исеме ыруг кешеләренең исеме булып та торган. Соңрак, вакытлар узу белән кешеләрне гаиләдә, коллективта бер-берсеннән аеру өчен аңа җисеменә туры килгән исем бирелә

башлаган. Шул рәвешле, ялгызлык исемнәр барлыкка килгән. Исем, барыннан да бигрәк, кешегә аерым атап мөрәҗәгать итү, бер кешене икенчесеннән аеру ихтыяҗын үтәү өчен хезмәт итә.

